Р.Н.ВӘЛИУЛЛИНА

# ИҢ ЯРАТКАН КӨЙЛӘРЕМ...

## ПЕСНИ КАЗАХСТАНСКИХ ТАТАР

Алматы—1994

**ББК 85.94**
**В23**

Выражаю глубокую благодарность Абузярову Ахмадулле Сафиевичу — директору МЧП «ДОРОЖНИК» за оказание помощи в выпуске этой книги.

*Валиуллина Р.Н.*

СПОНСОР — МЧНП и ВП «ДОРОЖНИК» — многоотраслевое Малое частное научно-производственное и внедренческое предприятие. Кроме основной деятельности — научно-производственной, технологической, изобретательской и других видов деятельности — наше предприятие занимается организацией издания книжной продукции, а также самостоятельно готовит книги к изданию.

Первая книга, вышедшая в конце 1993 года — «Интенсивный курс татарского языка для взрослых. На священной земле предков». Автор — профессор Абузяров Разак Абдрахманович, заведующий кафедрой русского языка и литературы Уральского педагогического института.

Вторая книга — в Ваших руках. Ее автор — Валиуллина Рамзия Нурулловна — музыковед-фольклорист, преподаватель кафедры теории музыки Алматинского Государственного университета им.Абая. Перу Р.Валиуллиной принадлежит ряд статей, посвященных татарской музыке в Казахстане и опубликованных в различных научных сборниках.

Готовятся к изданию книги:

1. Сборник татарских песен, пословиц, поговорок, свадебных традиций, сведений об истории татар. Это сборник материалов, опубликованных в разное время в журналах «Азат хатын», «Ялкын», «Казан утлары», «Идел», Сөембикә».

2. Любимые песни и традиции трех великих народов: Казахского, Татарского, Русского.

*А.С.Абузяров*

**Вәлиуллина Р.Н.**
**В23 Иң яраткан көйләрем...: Песни казахстанских татар.—Алматы: ТОО «Дайк-Пресс, 1994.—96 с.**
**ББК 85.94**

© ТОО «Дайк-Пресс» 1994

Халык җырларының шулай җәүһәр вә якутлардан да кыйммәтле бернәрсә булганы өчен дә, аларга әһәмият бирергә кирәк. Аларны югалтмаска иҗтиһат итәргә кирәк.

Белергә кирәк ки, халык җырлары — халкыбыз күңеленең һич тә тутыкмас вә күгәрмәс саф вә рәүшан көзгеседер. Бу — бертөрле сихерле көзгедер. Чөнки халыкның бер генә җыруын тотып нечкәләсәң, шөбһәсез, аның халәте рухиясен, нәрсә уйлаганын вә ни хакында нинди фикердә икәнен белеп буладыр.

*Габдулла Тукай*

Народные песни дороже жемчугов и рубинов — и потому их надо беречь, знать. Надо стараться не растерять их. Надо помнить о том, что народные песни — никогда не тускнеющее, чистое и прозрачное зеркало народной души. Это особенное, волшебное зеркало. Потому что, какую бы народную песню мы ни взяли, при тонком исследовании и изучении она, без сомнения, раскроет перед нами душу народа, расскажет о его чаяниях, поведает думы и мысли.

*Габдулла Тукай*

# Төзүчедән

Фольклорчылардан: «Туган „туфрагыннан" өзеп башка җиргә „утыртылган" яшәүгә сәләте булмый, халык иҗаты, сәнгате, гореф-гадәтләре тик шул халыкның борын-борыннан гомер иткән җирдә генә алга бара алалар, башка илләргә күчкән халыкның иҗаты сүрелеп, сүнеп калырга мәҗбүр», — дигән фикерне еш кына ишетергә туры килә.

Мин дә Казахстан татарларының музыка сәнгате буенча тикшерену эшенә керешкән вакытта шушы фикердән ерак түгел идем. Чынлап та, музыкабызның тамырлары Идел буйларында җәелгәне, тарихы Татарстан тарихы белән тыгыз бәйләнештә булганы һәркемгә мәгълүм. Шулай булгач, Татарстаннан башка җирләрдә яшәгән татарларның хәтерендә җыр сәнгате сакланып кала аламы, башка мохитнең эчендә җуелып китмиме?

Басым ясап әйтергә кирәк: Казах илендә тамыр җәйгән кардәшләребез милли мәдәниятнең матурлыгын һәм үзенчәлеген саклау белән генә чикләнеп калмастан, үзләре дә татар музыкасының традицияләрен алга сөреп, баетып киләләр. Фәнни тикшеренүләр нәтиҗәсендә Казахстан татарларының музыка мәдәнияте һәм иҗатының бик зур байлыклары ачылды; шул байлыкларның муллыгы җыентык төзүчесе өчен дә зур яңалык булды.

Халык җырчылары җыр классикасының борынгы үрнәкләрен буыннан буынга күчереп, күз карасы кебек саклап киләләр. Көйне орнаментлау, интонация ягыннан бизәкләү, иҗекләрне төрләндереп көйләү — татар халык җырларын башкару һөнәренең аерылгысыз үзенчәлекләре. Төрләндереп көйләү алымы бигрәк тә борынгы озын

көйләрне башкарганда кирәкле һәм урынлы. Казахстан татарларының яраткан җырлары арасында зур ихтирамга ия булган озын көйләр аз түгел. «Зиләйлүк», «Кара урман», «Салкын чишмә»,«Уел» кебек озын көйләр орнаментациянең төрле дәрәҗәләре белән башкарылалар. Бу китап өстендә эшләгән вакытта минә Тәнзилә Бахтеева (Петропавыл шәһәре), Хәят Каюмова (Шымкент), Маһинур Сираҗетдинова, Ләбибә Сермухамедова, Хәмидә Галиәкбарова (Алматы) кебек традицион вокал осталары, озын көйләрне искиткеч итеп башкара ала торган җырчылар белән очрашырга туры килде. Аларның җырлау һөнәрендә Казан татарларының лирик сәнгать стиле тулысынча сакланган. Шушы һәм башка җырчыларның башкаруы буенча язылган озын көйләр җыентыкның башында урнаштырылды.

Халык арасында киң таралган кайбер көйләрнең үзенчә язылганы музыка һәм җыр белгечләрен гаҗәпкә калдырмасын, чөнки җыр башкару формаларының күптөрлелеге — Казахстан татарларының музыка иҗатына хас һәм аның тартып алгысыз хасияте. Күп милләтле дәүләттә яшәгән халыкның һәркайсысы да илдәш халыкларның гореф-гадәтләрен, иҗади алымнарын үзләштереп килә, һәм бу табигый дә. Татар җырчыларының күбесе казах телен, казах вокалының традицияләрен бик яхшы беләләр, аларның репертуарларында казах җырлары аз түгел. Бу җырчылар татар җырларын башкарганда да кайвакыт казах, рус музыкасына хас элементларны кулланалар.

Казахстанда яшәүче халыкларның хәтерендә сакланып калган татар фольклорының иң борынгы төре — бәетләр: билгеле бер көйгә салып җырлана торган риваятьләр, хикәяләр, тарихы вакыйгалар турындагы истәлекләр. Борынгыдан күчеп килгән бәетләрнең кайберләре бүген дә тыңлаучыларның мәхәббәтенә ия булып, төрлечә башкарылып киләләр. Шуларның иң элек телгә алынырга тиешлеләре: ана каргышы төшеп сихри кошларга әйләнгән ике бала турындагы «Сак-Сок» бәете, «Суга баткан Гайшә», «Янып үлгән ике егет» бәетләре.

Бәетләргә якын, ләкин эчтәлеге дингә бәйле булганга аерылып торган үзенчәлекле жанр — мөнәҗәтләр. «Мөнәҗәт» сүзе гарәп теленнән чыккан, мәгънәсе — «Аллага ялвару», «Алла белән сөйләшү». Сәнгать күзлегеннән караганда, мөнәҗәт — шигъри нәфислек белән бизәлгән көй-монолог формасындагы дини тезмә әсәр. Шушы җыентыкка кергән мөнәҗәтләрнең үрнәкләре мөселман гореф-гадәтләре белгече Зөбәрҗәт Адиганова башкаруы буенча язылганнар.

Казахстанда таралган татар көйләренең бик еш очрый торган төре — салмак көй. «Сарман», «Арча», «Минзәлә» кебек туган якларга багышланган борынгы җырлар бүген дә популярлыгыннан аерылмастан халык мәхәббәтенә ия булып киләләр.

Шул ук вакытта киң таралган салмак көйләр арасында үзебезнең сәләтле музыкантлар һәм җырчыларыбыз иҗат иткәннәре аз түгел. Бу көйләр стилистика ягыннан типик халык көйләренә якын булсалар, иҗади үләштерүләр аркасында традицион татар музыка

теленнән аерылып торалар («Чуганак көе», «Сагыш җыры», «Яңа тәфтиләү»).

Салмак көйләр белән бергә кыска көйләр дә (такмак, бию көйләре, кунаклар белән дусларның хөрмәтенә җырлана торган җырлар, диалог-көйләр, теләк көйләре, шаян куплетлар) Казахстан татарлары арасында киң таралган. Кыска көй жанрында башкаручыларның поэтик һәм музыкаль иҗаты ачык күренеп тора. Җыентыкка кергән күп куплетлар ватандашларыбызның хәзер яшәгән өлкәләренә багышланган («Петропавыл такмаклары», «Бишкүл», «Алсу»). Бер үк җыр төрле җырчыларның башкаруында төрлечә яңгырый. Бер җырчы аны салмак кына, көен орнаментика белән бизәкләп башкарса, икенчесе шул ук җырны тиз, кызу дәрт белән җырлый. Һәркемгә таныш җырларның текстлары да күптөрле булып килә («Баламишкин көе», «Галиябану», «Каз канаты» һ.б.). Казахстан җырчылары куллана торган стилистик алымнарны күрсәтү максаты белән җыентыкка кайбер иң популяр җырларның берничә варианты кертелде.

Җыентыкның иң соңгы бүлеген Казахстан татарларының хәзерге иҗатын чагылдырып торган авторлык җырлар тәшкил итәләр. Авторларның күбесе — танылган «Сарман» ансамбленең (Алматы шәһәре) үзешчән артистлары.

Галимҗан Таминдаров — ансамбль җитәкчеләрнең берсе, өлкән педагогик стажы бар профессиональ музыкант, Казахстан Республикасы халык мәгарифенең атказанган эшчесе, татар һәм казах музыкасының зур белгече. Г.Таминдаров Петропавыл өлкәсендә туып үскән, Петропавыл татарларының фольклорын бик яхшы белә. Аның көйләре татар халык җырларының стилен саклап киләләр.

Г.Таминдаров үзенең җырларын күбесенчә «Сарман» ансамбльнең баш җитәкчесе һәм җырчысы Равил Гөзәиров белән бергә иҗат итә.

Яшь авторларның вәкилләре — Энҗе Гөзәирова һәм Шамил Сагаутдинов. Энҗе Гөзәирова — Алматы кызлар педагогика институтының хореография бүлегенең студенткасы, Шамил Сагаутдинов — Әл-Фараби исемендәге Казах дәүләт университетының өлкән гыйльми хезмәткәре. Икесе дә «Сарман» һәм «Алсу» ансамбльләрнең катнашчылары. Яшь авторларның көйләрендә хәзерге татар җырларына хас стиль ачык сизелеп тора.

«Минем мәхәббәтем» җырын язган Шәүкәт Сагаутдинов — үзешчән сәнгатьче, һәвәскәр музыкант, «Сарман» ансамбленең баянчысы. Көе яңа фольклор үрнәкләренә хас вальс ритмында язылган, мелодикасы халык җырларының мелодикасына якын.

Казахстан татарларының музыка иҗаты — республикабызның тарихы һәм мәдәниятенең аерып алгысыз өлеше. Татар җырлары әле XX гасырның 30-чы елларында ук танылган музыкант-этнограф А.В.Затаевичның игътибарын җәлеп иттеләр. Казах фольклорын җыеп йөргән вакытта ул Казахстанда яшәүче төрле халыкларның көйләрен язып барган. А.В.Затаевич татар җырларын төрле милләт вәкилләренең, шул исәптән татар, казах, башкортларның

башкаруы буенча язып алган. 1933 елны Мәскәүдә «Казахстан татарларының 50 җыры» дигән китабы басылып чыкты. Китапның эчендә хәзерге заманда да халык мәхәббәтенә ия булган «Алсу», «Галиябану», «Салкын чишмә», «Баламишкин» һ.б. халык җырлары бар. Китапның кереш сүзендә автор болай язган: «Башкаручылар төркемендә бик матур тавышлы һәм туган җыр әдәбиятеннән хәбәрдар кешеләр аз түгел булып чыкты. Алар үзләренең көйләрен яздыру өчен сизерлек мәхәббәт белән җырлап биргәннәр иде. Күбесенчә пентатоникага нигезләнеп язылган көйләр башкаручыдан нәфисләкне, зур осталыкны таләп итәләр».

Күренекле композитор Латыйф Хамиди дә Казахстандагы татар музыкасы буенча тикшерену үткәргән иде. «Казахстан татарларның халык музыкасы» дигән мәкаләсендә Л.А.Хамиди Казахстан шәһәрләрендәге татар музыка коллективларының иҗади эшләрен тасвирлаган, кин таралган җырларның башкару вариантларын тикшергән. Композитор шактый күп татар җырларын җыйган иде, ләкин, кызганычка каршы, шул материаллар басылып чыкмый калганнар. Югарыда әйтелгән мәкаләгә Л.А.Хамиди җыйган көйләрнең икесе генә («Алматы» һәм «Әминә») кергән.

Кызганычка каршы, А.В.Затаевич һәм Л.А.Хамиди җыйган кыйммәтле материаллар тулы түгел, мәсәлән, җырларның текстлары китерелмәгән. Безнең җыентыктагы җырларның исә, шул исәптән А.В.Затаевич белән Л.А.Хамиди әле гасыр башында ишеткән җырларның текстлары да, Казахстанда башкарыла торган төрле вариантлары да китерелгән.

Бу, әлбәттә, татар музыка мәдәнияте дигән чиксез зур күренешнең кечкенә өлеше генә. Шулай булса да, милли мәдәният традицияләрен, халык җырларын бәяли белүчеләр табылыр, татар җыры музыкаль агымнары бик күп булган безнең заманда да күп милләтле Казахстан мәдәниятенең бер әһәмиятле өлеше булып калыр дигән өмет күңелне җылытып, ялкынландырып тора.

Сүзнең ахырында бөя биреп бетергесез ярдәм күрсәткән фәнни җитәкчем доцент Г.К.Котловага, рецензия язган профессор А.Е.Байгаскина һәм доцент С.А.Елемановага, Алматы шәһәренең Татар мәдәни үзәге һәм «Сарман» ансамбленең әгъзаларына, халык традицияләрен нык саклап килгән барлык хәбәрчеләремә чиксез зур рәхмәт әйтәсем килә.

*Р.Н.Вәлиуллина*

## От составителя

Среди фольклористов бытует мнение, что фольклор, «пересаженный на другую почву», не жизнеспособен, что народное творчество, народные традиции могут полноценно развиваться только на исконной земле, в тех местах, где зародилось искусство данного народа. Творчество же переселенцев с годами угасает, не получая необходимой «подпитки», в окружении иных национальных традиций, иной природы, иных жизненных условий.

С таким предубеждением приступала я к изучению музыкального искусства казахстанских татар. Ведь, как известно, истоки нашей музыки уходят в Поволжье, в глубины истории Татарстана. Сохранилось ли песенное искусство в памяти народа, не стерлось ли с годами, не растворилось ли в соприкосновении с иной средой?

Подлинным откровением для собирателя стало обнаруженное богатство музыкальной культуры, народного творчества татар, издавна живущих на землях Казахстана. Народ наш не только сохранил в веках истинную красоту и самобытность национальной культуры, но и продолжает творчески развивать и обогащать традиции татарской песни.

Из поколения в поколение народные певцы бережно сохраняют в памяти старинные образцы песенной классики. Особым искусством в татарском пении считается умение орнаментировать напев, расцвечивать мелодию интонационными узорами, украшать песню богатым распевом слогов. Подобный распев очень важен при исполнении старинных протяжных напевов — озын көй. В среде казахстанских татар есть ряд протяжных песен, особо любимых и чтимых. Такие мелодии, как «Зиләйлүк», «Кара урман», «Салкын чишмә», «Уел» и другие, исполняются во множестве вариантов с различной степенью орнаментации.

В процессе работы мне довелось встретиться с замечательными исполнителями протяжных напевов, мастерами традиционного вокала. Это Танзиля Бахтеева в Петропавловске, Хаят Каюмова в Шымкенте, Магинур Сиразитдинова, Лябиба Сермухамедова, Хамида Галиакберова в Алматы. Их исполнительство сохраняет подлинный стиль лирического искусства казанских татар. Протяжные песни, записанные от этих певиц и многих других исполнителей, открывают сборник.

Любителей и знатоков татарской песни может удивить своеобразное звучание некоторых хорошо известных народных мелодий, иная подтекстовка, изменения в форме напевов. Но именно

богатством вариантов, большим разнообразием в исполнительстве отличается музыкальное творчество казахстанских татар. Ведь живя в многонациональной среде, невольно перенимаешь из окружения и обычаи, и традиции, и творческие приемы. Немало татарских певцов имеют в своем репертуаре и популярные казахские песни, прекрасно владеют казахским языком, стилем традиционного казахского вокала. И в пении некоторых татарских певцов порой встречаются интонации, характерные для казахской музыки. Встречаются в татарских вариантах и элементы заимствования из русской мелодики.

Наиболее древний жанр татарского фольклора, сохранившийся в памяти казахстанцев — это баиты. Баиты представляют собой музыкальный эпос: старинные легенды, сказания, воспоминания об исторических событиях, которые по традиции исполняют, напевая на определенную мелодию. Некоторые из древнейших баитов и по сей день пользуются большой любовью среди слушателей и исполнителей в различных интерпретациях. Это, прежде всего, хорошо известный баит «Сак-Сок» — сказочное повествование о двух мальчиках, превратившихся проклятием матери в фантастических птиц Сак и Сок. Это и грустно-поэтический баит «Суга баткан Гайшә» («Об утонувшей Гайше»), и многие другие.

Своеобразный жанр, близкий к баитам, но, в отличие от них, имеющий религиозное содержание, — мнажаты. Слово «мнажат» арабского происхождения; переводится как «молитва», «беседа с богом». Мнажаты — напевы-монологи, своего рода поэтическое, художественно оформленное обращение к богу. Образцы, вошедшие в данный сборник, исполнила прекрасный знаток мусульманских традиций Зебаржат Адиганова.

Самым распространенным жанром татарской песни в Казахстане являются умеренные лирические песни — салмак көй. Среди них — множество созданных в давнее время в селах и городах Татарстана и получивших названия в память о родных краях: «Сарман», «Арча», «Минзәлә». Эти песни не утратили своей популярности, и по сей день не менее любимы и исполняемы. Однако, немало новых лирических песен типа «салмак көй» было создано талантливыми музыкантами и певцами и в наших краях. Зачастую мелодии этих песен приобретают характер творческих заимствований, отличаясь от традиционного музыкального языка татар («Чугачак көе», «Сагыш жыры», «Яңа тәфтиләү»), порой стилистически приближаются к образцам типичной народной песни.

По степени популярности с напевами «салмак» могут сравниться лишь так называемые «кыска көй» — короткие напевы. Это и частушки, и плясовые наигрыши, и различного рода гостевые, дружеские песни-посвящения, песни-диалоги, песни-пожелания, шуточные куплеты. В жанре «кыска көй» так же, как и в песнях «салмак», в наибольшей степени проявилось поэтическое и музыкальное творчество исполнителей. Немало куплетов посвящено тем краям, в которых ныне живут наши соотечественники («Петропавыл так-

маклары», «Бишкуль», «Алсу»). Одна и та же песня, одна и та же мелодия в устах разных исполнителей и звучит по-своему. Один певец исполнит ее в умеренном темпе, расцветив мелодию орнаментикой, другой — ту же песню споет оживленно, энергично. Хорошо известные напевы существуют с самыми различными текстами, в различных интерпретациях («Баламишкин көе», «Галиябану», «Каз канаты» и др.). В сборник включены наиболее популярные песни в нескольких исполнительских трактовках, что было вызвано стремлением показать наиболее характерные стилистические приемы, используемые нашими, казахстанскими певцами.

Последний раздел сборника содержит авторские песни — образцы современного творчества татар в Казахстане. Авторы данных песен — по большей части самодеятельные артисты, участники известного алматинского ансамбля «Сарман».

Галимжан Таминдаров — один из руководителей ансамбля «Сарман», профессиональный музыкант с многолетним стажем педагогической деятельности, заслуженный работник народного образования Республики Казахстан, большой знаток как татарской, так и казахской музыки. Г.Таминдаров родом из Петропавловской области и хорошо знаком с фольклором петропавловских татар. Его песенные мелодии во многом сохраняют народный стиль татарской песни. Любопытно, что в ряде песен музыкант использует старинные лады, характерные для наиболее ранних образцов татарской песни — так называемую бестерцовую пентатонику. Большинство своих песен Г.Таминдаров создает в содружестве с Равилем Гузаировым, также руководителем и активным участником ансамбля «Сарман».

Представители молодого поколения — Энжи Гузаирова и Шамиль Сагаутдинов. Энжи Гузаирова — студентка Алматинского женского педагогического института, отделения хореографии. Шамиль Сагаутдинов — старший научный сотрудник Казахского государственного университета им. Аль-Фараби, кандидат физико-математических наук. Оба — участники художественной самодеятельности в татарских ансамблях «Сарман» и «Алсу». Мелодии молодых авторов отражают стиль, характерный для современной татарской песни. Автор песни «Минем мәхәббәтем» — Шавкат Сагаутдинов — также участник художественной самодеятельности, музыкант-любитель, один из баянистов ансамбля «Сарман». Песня написана в характерном для образцов нового фольклора вальсовом ритме в сочетании с типичной для народных песен мелодикой.

Музыкальное творчество казахстанских татар — неотъемлемая часть истории и культуры нашей республики. Еше в 30-е годы нашего столетия татарские песни привлекли внимание известного музыканта-этнографа А.В.Затаевича. Собирая казахский фольклор, музыкант попутно записывал мелодии разных народов, живущих в Казахстане. Татарские песни А.В.Затаевич зафиксировал от исполнителей разных национальностей, среди которых были татары, казахи, башкиры. В 1933 году в Москве была издана книга

«50 песен казахстанских татар». В ней есть записи мелодий, популярных и любимых в народе и по сей день. Это «Алсу», «Галиябану», «Салкын чишмә», «Баламишкин» и другие. В предисловии к книге автор писал: «В группе исполнителей оказалось немало лиц, обладающих очень красивыми голосами, и, главное, хорошо осведомленных в родной песенной литературе. Они с видимой любовью передавали мне для записи свои напевы, своеобразная мелодия которых, вытканная, главным образом, на основе пентатоники, требует от исполнителя особенно четкой, филигранной, нигде не смазанной передачи.»

Изучал татарскую музыку в Казахстане и известный композитор Латыф Хамиди. В своей статье «Народная музыка казахстанских татар»[1] Л.А.Хамиди приводит факты творческой деятельности татарских музыкальных коллективов в городах Казахстана, анализирует варианты исполнения известных песен. Композитор также собирал и записывал татарские песни, но, к сожалению, эти материалы не были опубликованы. Лишь две мелодии, записанные Л.А.Хамиди, напечатаны в указанной статье. Это нотные тексты песен «Алма-Ата» и «Әминә».

К большому сожалению, уникальный материал, собранный А.В.Затаевичем и Л.А.Хамиди, не полон: к нотным записям мелодий не даны тексты. В нашем сборнике песни — а среди них и те, которые пелись в начале века и были услышаны А.Затаевичем и Л.Хамиди — представлены уже с поэтическими текстами, так, как поют их у нас, в Казахстане.

Конечно же, это лишь малая часть того огромного, необъятного явления, что представляет собой татарская музыкальная культура. И хочется верить, что национальные культурные традиции, народная песня всегда найдут своих ценителей и знатоков, что в наше время, богатое разнообразием музыкальных увлечений, татарская песня останется, как и в прошлом, одной из составляющих в сложном спектре многонациональной культуры Казахстана.

Считаю своим долгом выразить глубокую благодарность своему научному руководителю, доценту Г.К.Котловой, рецензентам профессору А.Е.Байгаскиной и доценту С.А.Елемановой, членам Татарского культурного центра г.Алматы и татарского ансамбля «Сарман», а также всем моим информаторам — хранителям народной традиции, с кем довелось мне встретиться в работе.

*Р.Н.Валиуллина*

[1] В книге «Народная музыка в Казахстане», Алма-Ата, 1967.

# I. Озын көйләр

## № 1. Аппагым, җанашым




Борылып, борылып аккан, ла, су янында,
Аппагым, җанашым,
Өзелеп-өзелеп җырлар, ла, җырладым.

Өзелеп-өзелеп җырлар, ла, җырладым, да,
Аппагым, җанашым,
Түзәлмичә өзелеп җыладым.

# № 2. Зөлхиҗҗә




Ялан да гына җирләрдән, ой, болан килә, ой, Зөлхиҗҗә,
Уйсу гына, ой, җирләрдән, ай, үтәм дип, Зөлхиҗҗә.

Төн уртасы җиткәч тә, бер кыз елый, Зөлхиҗҗә,
Яшь гомерем заяга, ай, үтә, дип, Зөлхиҗҗә.

## № 3а. Уел.




Сахраларга керсəм, үлəн сирəк,
Урманнарга чыксам, җир җилəк.

Эчемдə генə минем утлар яна,
Ник җилкенə икəн бу йөрəк?

## № 3б. Уел




Күтеп алсам еллык бəйрəмлəрне,
Бəйрəмлəр дə шатлык бирə алмый,

Бəйрəм килсə йөзем көлгəн була,
Шатлык белəн йөрəк тибə алмый.

# № 4. Гөлҗамал




Шәмдәлләрдә генә утлар яна, Гөлҗамал,
Җиткән кызлар киндер җеп эрлиләр.
Энҗе лә мәрҗән кызларның кул бавы,
Авыр җан сөйгәннәрнең булмавы.

Нинди генә егеткә барырбыз, дип, Гөлҗамал,
Колактан колакка алар сөйлиләр.
Энҗе лә мәрҗән кызларның кул бавы,
Авыр җан сөйгәннәрнең булмавы.

## № 5. Тәфтиләү




И мөкатдәс, моңлы сазым! Уйнадың син ник бик аз?
Син сынасың, мин сүнөмен, айрылабыз ахрысы!

Очты дөнья читлегеннән тарсынып күңелем кошы,
Шат яратса да, җиһанга ят яраткан раббысы.

## № 6а. Зиләйлүк




Сөялгәнсең, бәгърем, баганага,
Яфрак төсле сары йөзләрең; (2)
Уфтанмыйча күңлем чыдый алмый,
Зиләйлүк,
Бигрәк моңлы карый күзләрең. (2)

## 6б. Зиләйлүк




Таң атканда торып тыңлар идем
Былбыл кошкайларның тавышын;
Былбыл кошлар кебек җырлап түгәм,
Зиләйлүк,
Күкрәгемнән кайгы сагышын.

## № 7. Һаваларда йолдыз




Һаваларда йолдыз, ай, ничәдер?
Ничә санасаң да күчәдер.
Һаваларда йолдыз, суларда кондыз,
Газизәкәй балдыз, елама,
Калмассың ялгыз.
Ничә генә айлар, ничә еллар
Сине уйлап гомерем кичәдер.
Һаваларда йолдыз, суларда кондыз,
Газизәкәй балдыз, елама,
Калмассың ялгыз.

## № 8. Салкын чишмә




3–716

Зәңгәр айлы кичтә ташка басып,
Салкын чишмәләрдән су алдым.
   Тау астында салкын чишмә
   Чылтыр-чылтыр агадыр;
   Иҗтиһат ит, эшкә башла,
   Гомер үтеп барадыр.
Салкын чишмәләрдән су алганда
Шушы җырларымны җырладым.
   Тау астында салкын чишмә
   Чылтыр-чылтыр агадыр;
   Иҗтиһат ит, эшкә башла,
   Гомер үтеп барадыр.

## № 9. Үкенү




Агыйделкәй ялкын, суы салкын,
Ак үрдәкләр каршы йөзә алмый.
   Сикереп төштем, сулар эчтем
   Нигә төштем, ник эчтем?
   Бу хәсрәтне күрер булгач
   Нигә тудым, ник үстем?

Үткән гомерләрне искә алганда
Бер җырламый күнелем түзә алмый.
   Сикереп төштем, сулар эчтем,
   Нигә төштем, ник эчтем?
   Бу хәсрәтне күрер булгач
   Нигә тудым, ник үстем?

## № 10. Сәгать чылбыры




Иртә томан, кичтә томан,
Томан азагыннан чык булган.
    Ай, югалттым сәгать чылбырым,
    Тапмадыңмы, сары былбылым?

Син килерсең мине эзләп —
Шул чакларда, жаныем, мин булмам.
    Ай, хәсрәт өчен үскән икән
    Минем газиз башкаем,
    Читен хәл, авыр, жанашым.

## № 11. Ашказар




Җанкай, җанаш китте, ай, сунарга,
Ашказаркай буена, чәшкегә.
Чәшкеләргә китеп, вафат булды,
Газиз башым калды, ла, яшь көйгә.

Ай уймакай кебек сызылып ага
Ашказаркай суының алкыны;
Күкрәгемне генә яндырадыр
Яшь йөрәккәемнең ялкыны.

## № 12а. Кара урман




Кара да гнай урман, караңгы төн,
Яхшы атлар кирәк, лә, үтәргә,
Карурманны чыккан чакта
Кисеп алдым пар усак.
Эй! аерылмаек дус булсак.

## № 12б. Кара урман



Каралай урман гына, караңгы төн,
Яхшы атлар кирәк үтәргә.
Карурманга кергән чакта
Атлар төшми елгага.
Ай! Дус-иш кирәк дөньяда.

Кимим бүрегем булса да,
Җырламыйм, күңелем тулса да.
Алла язгач, ни хәл итим,
Чыдыйм, авыр булса да.

## № 12в. Кара урман




Кара да гнай урман, караңгы төн,
Яхшы атлар кирәк, лә, үтәргә.
Кара урман чыккан чакта
Кисеп алдым пар усак.
Ай! аерылмаек дус булсак.

Кара да гнай урман, караңгы төн,
Нинди юллар белән, лә, үтәрбез.
Кара урман чыккан чакта
Кисеп алдым пар каен.
Ай! аерылмаек, дускаем.

# № 12г. Кара урман



Кара да гнай урман, караңгы төн,
Яхшы атлар кирәк үтәргә.
Карурманга кергән чакта
Кисеп алдым пар каен.
Эй! аерылмаек, дускаем.

Дус-иш кирәк, дус-иш кирәк
Дөньялар гына көтәргәй.
Карурманга кергән чакта
Кисеп алдым пар нарат.
Эй! калды-иш тилмереп карап.

Алай гына, болай, шулай сипап,
Атланаек, дуслар, бер атка.
Карурманга кергән чакта
Кисеп алдым пар каен.
Эй! аерылмаек, дускаем.

Атлансак, дуслар, бер атка
Ирешербез генә моратка.
Карурманга кергән чакта
Кисеп алдым пар нарат.
Эй! калды-иш тилмереп карап.

## № 13. Карурман аша




Җитәсе, лә, җиргә мин җитә алмыйм;
Ни булды икән миңа, туры атка, шул.
Карурман аша, карурман аша
Кошлар сайраша, шул, башлар адаша.

Күпер башкайлары, әй, күк чәчкә,
Чәчкә башкайлары, кер эчкә, шул.
Карурман аша, карурман аша
Кошлар сайраша, шул, башлар адаша.

Сабырлар солтан, сабырсыз шайтан,
Сабырлык кирәк һәр эштә шул.
Карурман аша, карурман аша
Кошлар сайраша, шул, башлар адаша.

4–716

## II Бәетләр

### № 14а. Сак-Сок




Мәдрәсәләрдә китап киштәсе,
Сак белән Сокның бәетен иштәсе.
Мамык эшләпәм җилгә очырдым,
Ике баламны каргап очырдым.
Безләр талаштык тимер ук өчен,
Әнкәй каргады бер дә юк өчен.
Әнкәй каргады, әткәй, белдеңме?
Турыдан уздык, әткәй, күрдеңме?
Кыямәт көнсез күрешү юк безгә,
Кавышабыз дисәк, кан тула күзгә.

### № 14б. Сак-Сок




Мәдрәсәләрдә китап киштәсе
Сак белән Сокның бәетен иштәсе.
Әткәй калдырды, өйдә торсын, дип,
Әнкәй каргады, Сак-Сок булсын дип.
Бардык урманга, җыйдык карлыган,
Без ятимнәрне әнкәй каргаган.
Әнкәй каргагач Сак-Сок булдык без,
Бу дөньялардан гыйбрәт алдык без.

## № 15а. Сак-Сок




Мәдрәсәләрдә китап киштәсе,
Сак белән Сокның бәетен иштәсе.
Әнкәй каргаган тимер ук өчен,
Каргап очырган бер дә юк өчен.

## 15б. Сак-Сок




Мәдрәсәләрдә пыяла ишек,
Сак белән Сокның бәетен ишет.
Ишек алдында җигүле пар ат;
Әнкәй каргагач яралды канат.
Каргап җибәрде, эшне бетерде,
Безләр хуш булгач үзе үкенде.
Әнкәй каргады мылтык угы өчен,
Каргап очырды бер дә юк өчен.
Кумач күлмәгем бер дә кимәдем,
Очып киткәндә сау бул димәдем.
Җөйгән кисмәннең калмады берсе,
Ике баланның калмады берсе.
Әнкәй, бишмәтең биле кысадыр,
Урман буенда йөрәгең сызадыр.
Әнкәй, тәрәзәңә буран уйгәндер,
Без очып киткәч бәгърен көйгәндер.
Әнкәй сандыгын ачып куядыр,
Кайгыдан әнкәй ашамый туядыр.
Әнкәй, токмачлы ашың пешкәндер,
Без очып киткәч эчең пошкандыр.

## № 15в. Сак-Сок




Мәдрәсәләрдә китап киштәсе,
Сак белән Сокның бәетен иштәсе.
Әнкәй орышты тимер ук өчен,
Әнкәй каргады бигрәк юк өчен.
Самовар куйды, чәйләр эчерде,.
Эчеп бетергәч, каргап очырды.
Әткәй калдырды, өйдә торсын, дип,
Әнкәй каргады, Сак-Сок булсын дип.
Кыйбла ягыннан җилләр исәдер,
Безнең ризыкны әнкәй кисәдер.
Өйгән кибәнне җилләр тарата,
Кавышыбыз дигәч, хәзер таң ата.
Кояш чыкканда кан тула күзгә,
Кыямәт көнсез кавышу юк безгә.
Бардым урманга, кистем пар каен,
Газиз әнкәмне сагынам көн саен.
Мамык эшләпә алып кайтыгыз,
Әнкәйне күргәч, сәләм әйтегез.
Әнкәй, елама, нигә елыйсың,
Үзең каргагач, үзең чыдыйсың.
Мендем ботакка, карадым як-якка,
Ике баламны каргадым юкка.
Якты дөньяны күрми калабыз,
Каргады безне газиз анабыз.
Йокыга киткәч, бер төш күрдек без,
Җәй көннәрендә ялгыз йөрдек без.

## № 16. Ямщик бәете




Ачы җил буран тавышы ишталә,
Таң сахрасында яшь ямщик үлә.
Сизәдер мескен әшәл җиткәнен,
Чакыра янына якын иптәшен.
— А иптәшкәем, мин бүген үләм.
Таң сахрасында күмәрсең мине.
Кара атымны тапшыр әткәмә,
Кайнар сәләмем газиз әнкәмә.
Әйт хатыныма, мине көтмәсен,
Үзенә башка иптәш эзләсен.
Әйт хатыныма, мин туңып үләм,
Аның гыйшыгын мин алып үләм.
Әйт хатыныма ошбу сүземне,
Кулымнан алып бир йөзегемне.
Инде ямщикның актык сүзләре,
Йомылып китте кара күзләре.
Таң сахрасында вак-вак кар ява,
Ямщикның аты моңаеп бара.

## № 17. Кара син алга




Кара син алга, күрәсең анда,
Кызыл байракны буяган канга.
Кеше эшчеләр күтәргән аны,
һәммә байрактан тора югары.

## № 18а. Суга баткан Гайшә




Чәршәмбе көн кер чайкайга
Ник җибәрдең, әнкәем?
Барма, Гайшә, дигән булсаң,
Бармас идем, әнкәем.

Чәршәмбе көн мунча яктым
Башым-күзем юарга.
Чәршәмбе көн кер чайкадым
Газиз башым җуярга.

Өстемдәге ал күлмәгем
Батадыр да калкадыр.
Чәчемдәге талир тәңкә
Су төбенә тартадыр.

## № 18б. Суга баткан Гайшә




Чәршәмбе көн кер чайкадым
Су буенда, әнкәем.
Барма, Гайшәм, дигән булсаң,
Бармас идем, әнкәем.

Өстемдәге атлас күлмәк
Калкый бер дә балкыйдыр.
Чәчемдәге алтын тәңкә
Су астына тартадыр.

Өстемдәге камзолымны
Элеп куйдым казыкка.
Зифа буем үскән икән
Балыкларга азыкка.

## № 18в. Суга баткан Гайшә




Чәршәмбе көн кер юарга ник җибәрдең, әнкәем?
Барма, Гайшә, дигән булсаң, бармас идем, әнкәем.
Кулымдагы көмеш йөзек көнгә каршы.эридер.
Тал чыбыктай зифа буем су төбендә черидер.
Өстемдәге камзулымны элеп куйдым казыкка,
Зифа буем үскән икән балыкларга азыкка.
Баткан чакта итәкләрем батадыр да калкадыр,
Муенымдагы төңкәләрем су төбенә тартадыр.
Аучы мылтык атадыр, төтене җиргә ятадыр,
Матур Гайшә баткан дигәч, туе җылап кайтадыр.
Чәршәмбе көн мунча яктым, битем-күзем юарга,
Чәршәмбе көн кер чайкадым, газиз башым җуярга.

## 19. Әткәемне көтәм әле




Әткәемә хәбәр килде сугышларга китәргә,
Бер янамын, бер көямен, белмим нихәл итәргә.
Безнең әткәй киткән чакта кара бишмәтен киде,
Германнарны илдән кугач, шаять, кайтырмын, диде.
Әткәй яткан окопларның авызлары тар микән,
Германнарны илдән куып, күрешер көннәр бар микән,
Әткәй торткан киртәләргә карлыгачлар тезелә,
Шул әткәйне төштә күрсәм, үзәкләрем өзелә.
Аклы ситса күлмәгемне әткәй кайткач киярмен,
Әгәр әткәем кайтмаса, кемгә әткәй диярмен?
Әткәй киткәч тугыз көндә сугышка барып керде,
Дүрт ай буе исән йөреп, бишенче айда үлде.
Әткәемне көтәм әле, көтәм әле үлсә дә,
Военкомат өстәленә публигы килсә дә.

Ал юам елгаларда, гөл юам елгаларда.
Ятим калудан авыр хәл юк икән дөньяларда.
Әткәемне армияга алып китте машина,
Машина түгел, ач Гитлер җитте әткәй башына.
Әткәй, бәгърем, син үл инде, синең өчен яшьләр түгелсен
Сугыш кырларында үлеп калдың, әтием,
Кабер өсләрендә гөл үссен.

## 20. Уза яшь гомер




Әй, син, картлыгым, ник иртә килдең,
Мин картайганны син кайдан белдең?
Яшь вакытларым, кая киттең син,
Картайтып мине ямьсез иттең син.
Алсу йөзләрнең нуры китә икән,
Яшьлек гомерләр бик тиз үтә икән.
Яшьлек чәчәгем өзелеп кипте,
Искән җил кебек исте дә китте.
Күңелле икән яшьлек чагында,
Әйләнеп кайтмый тик ул тагын да.
Ул вакытларны, әй, бер күрергә!
Төштә күргән тик калды күңелдә.
Картлык хәлләре яманпу икән.
Тиз килеп җитте - агым су икән.

Бу чәчләремә нигә ак төшә,
Яшьлегем белән картлык тартыша.
Картлык көчле икән, яшьлекне җиңде,
Эй, яшьлегем, китәсең инде.
Йоклый алмыйча чыгам төннәрдә,
Кадерсез калмыйк картлык көннәрдә.
Бер картайгачтын ямьләр тапмыйсың,
Ашыкма, гомер, кире кайтмыйсың.
Авыр тормышлар уздылар күптән,
Бу яшь гомерне күрмәмен бүтән.
Иртә торгачтын кичләрне көтәм,
Яшь гомер китте, килмәм дип бүтән.
Кагазьлар язып куямын бөкләп,
Китте яшь гомер кулларын селтәп.
Мәңгелек йортка барып җитәрбез,
Тапкан малларны ташлап китәрбез.
Кемнәр тумаган, кемнәр булмаган,
Пигамбәрләр дә мәңге тормаган.

## № 21. Солдат бәете




Бисмиллаһи-ир-рахмани,
Җитте корбан гаете.
Без әйтиек, сез тыңлагыз
Мескен солдат бәетен.

Солдат кия сары итек
Кунычларын тар итеп;
Без солдатка киткән чакта
Калды дуслар зар итеп.

Без барасы, эй, юлларның
Ике чите канавлы;
Күп торбамыз, күп сүнмәгез
Безнең көннәр санаулы.

Чүен чүлмәкләр эчендә
Пешә солдат ашлары.
Аккош очып җитмәс җиргә
Китә солдат башлары.

Дошман мылтыгын атадыр,
Тәтене җиргә ятадыр.
Я кәфен юк, я кабер юк
Үлегебез җирдә ятадыр.

## № 22. Мөнәҗәт




И иллөһем, иллөһем,
Күптер, бөнем, гөнаһем,
Гөнаһемне гафу өйлөп
Рөхмөт кылгыл иллөһем.

Иллөһем сүзе Көръөн,
Пигөмбөремө килгөн.
Безгө ул китап булган
Бердер иллөһем, бөнем.

Ул иллөһем терекдер,
Аңа үлмөк һич юкдыр.
Көченең чиге юкдыр.
Бердер иллөһем, бөнем.

Сакла, ходай, үземне,
Нөмөхремдин күземне,
Кыямөт көне булганда
Кара кылма йөземне.

И ходаем, хур итмө,
Талигымни ким итмө,
Көндин көнгө төуфик бир,
Барчабызны ярлыкка.

Сират күперен кичкөндө
Табынымны тайдырма.
Гаишө илө Фатыйма,
Хөдичө и Көбераны
Юлдашкылгыл сөн, алла.

## № 23. Мөнәҗәт




Үлдең исө юарлар,
Төненө көфен сарырлар,
Илтеп гүргө куярлар,
Нө кылмышыңны язарсың?

Бармакларың калөм булыр,
Күз яшьлөрең кара булыр,
Кәфенлөрең кагаз булыр,
Нө кылмышыңны язарсын?

Менө алмыйм тау башына,
Баса алмыйм ташына,
Сөфөрем ерак — юк азыгым,
Ни өйтермен хак каршында?

# III Салмак көйләр

## № 24. Бишкүл




Алдыр Бишкүл буйлары,
Гөлдер Бишкүл буйлары.
Ал булса да, гөл булса да,
Калды Бишкүл буйлары.
Бишкул күле — түгәрәк күл,
Әйләнәсе гөлгенә;
Сагынганда кайтам сиңа,
Син бит минем бер генә.

## № 25а. Кошлар




Һаваларда очкан аккошларның
Канат каурыйлары, ла, күлләрдә, шул.
Хаты да юк, җылы сүзе дә юк,
Калды инде сагнып, ла, сөйләргә.

Һаваларда очкан аккошларның
Авызында сары, ла, балавыз, шул,
Әткәй-әнкәй, мине онытма,
Мин дә сезнең газиз, ла, балагыз.

## № 25б. Кошлар көенә




Уфаларга барган чакта
Агыйдел буен, буена.
Ачык та көнне, явым, ла, яуса
Мине сагынды дип уйла.

Аргы урамнан килдеңме,
Бирге урамнан килдеңме?
Мин сагынганны белдеңме,
Сагынып та үзең килдеңме?

## № 26. Аппакай-алмакай.




Җырлый-җырлый чәчәк җыям, чәчәк җыям,
Урал сулар буеннан, буеннан.
Аппакай-алмакай,
Урал сулар буеннан, буеннан.

Каенлыкта шаулый-шаулый, сөенә-сөенә
Җиләк җыя авыл кызы Мөнирә
Аппакай-алмакай,
Маңгай чәчен артка сирпеп бөгелә.

## № 27. Зәйнәбем




Һаваларда йолдызларны
Нигәдер санамадым, шул, Зәйнәбем.
Ал, Зәйнәбем, гөл, Зәйнәбем,
Рәхәт үтсен җәйләрең.

Күз тияр дип йөзләренә
Нигәдер карамадым, шул, Зәйнәбем.
Ал, Зәйнәбем, гөл, Зәйнәбем,
Рәхәт үтсен җәйләрең.

Алсу гөлем, алсу гөлем,
Алсу гөлләрем син шул, Зәйнәбем.
Ал, Зәйнәбем, гөл, Зәйнәбем,
Рәхәт үтсен җәйләрең.

## № 28. Шахтер көе




Шахтер көе, шахтер көе,
Шахтер көе моңлы көй, шул,
Моңсызларны, уйсызларны
Уйлатыра торган көй.

Шахтер көе, шахтер көе,
Шахтер көен яратам, шул,
Шахтер көйләрен җырласам,
Бар хәсрәтем таратам.

Сагынам, дуслар, сагынам, дуслар,
Сагынам, дуслар, белмисез, шул;
Бик сагынган көннәремне
Төшемә дә, лә, кермисез.

Сузып уйна гармуныңны,
Бик матур уйнатасың, шул,
Уйнатасың, уйлатасың,
Күңелемне юатасың.

## № 29. Шомыртым




Өй артында шомыртым бар,
Яннарында, ла, бөрлегән, шул,
Яннарында, ла бөрлегән.
Сине, лә, сагынам, сине көтәм,
Син бит минем бергенәм.

Өй артында шомыртым бар,
Чәчәкләр яннарында, шул,
Чәчәкләр яннарында;
Без туганбыз илебезнең
Ин матур таңнарында.

## № 30. Бәйбәтчә көе




Абыем миңа ат бирде, лә,
Иярлә дә чап, диде;
Кайда матур кызлар күрсәң —
Кочаклап-алып кач, диде.

Сары ат мендем, сазлар кичтем,
Сары ат салкыннасын дип.
Урамнардан чабып үттем,
Кызлар хайран калсын дип.

## № 31а. Алсу




Алматының алсулары
Биек таулардан килә.
Алсу, алсу, йөрәккәем ярсу,
Баса алмый салкын су.

Алматының тауларында
Пешә кызыл бөрлегән;
Сине генә көтөм, сине генә сөям,
Син бит минем бергенәм.

Алматыга барган чакта
Бик күп сулардан үтөм;
Синә генә сөям, сине генә көтөм,
Кирәкми миңа бүтән.

Алматының тауларыннан
Ага суның салкыны;
Су сипсәң дә, сүнәр түгел
Йөрәгемнең ярсуы.

## № 31б.Алсу




Алсу, алсу, алсу,алсу,
Алсу көен яратам.
Алсу көен уйнаганда
Бар хәсрәтем таратам.

Алсу, алсу, ал күлмәгең
Алсуга мандыңмыллә?
Бигрәк тә сүрән утырасың,
Ярыңдан калдыңмыллә?

## № 32. Дим-дим




Җилфер-җилфер, дим-дим, йөргән чакта, дим-дим,
Җилләре ача, ла, куенымны.
Янып-көеп, дим-дим, йөргән чакта, дим-дим,
Дусларым ача, ла, күңелемне.

Җилфер-җилфер, дим-дим, итүе, лә, дим-дим,
Җилнең алып китүе.
Күңелле дус, дим-дим, ишләр белән, дим-дим,
Бергә гомер итүе.

Җилфер- җилфер, дим-дим, ука чуклар, дим-дим,
Ник җилферди, җил дә юк?
Синең кебек, дим-дим, матур ярлар, дим-дим,
Авылда түгел, илдә юк.

## № 33. Авыл көе



Син-син савытларым тулмый,
Син-синнәр тутырсам да.
Синсез күңелләрем булмый,
Кайларда утырсам да.

Сахраларда зәңгәр чәчәк
Уралган каеннарга.
Мин дә зәңгәр чәчәк идем,
Уралдым кайгыларга.

## № 34. Мәрфуга




Агыйделгә барган чакта, барган чакта,
Сындырмадым багырымны, Мәрфуга.
Ой, ли, гөл Мәрфуга, бар суга.
Гөл Мәрфуга, барсаң суга,
Сөйләшербез барсында.
Гөл Мәрфуга, барсаң суга,
Янган йөрәк басыла.

## № 35а. Рамай




Төнгә каршы бераү монлы итеп, Рамай,
Аерылышу көен уйнады.
Тынга калды урман буйлары да, Рамай,
Чишмәләрдәй акмый тыңлады.

Китәм инде, иркәм, мин еракка, Рамай,
Сөйгән дустым, синнән аерылып.
Бер сагынганда, ла, бер карарсын, Рамай,
Киткән юлларыма, ла, каерылып.

Сахраларга чыктым кош атарга, Рамай,
Оялары калган, кошы юк.
Гәүдәләрең тора күз алдымда, Рамай,
Сөйләшергә генә үзең юк.

## № 35б. Рамай




Агыйделкәй алкын, суы салкын, Рамай,
Дәрия суларыннан ким түгел.
Кеше кешеләрдән артык түгел, Рамай,
Тик бәхеткәйләре тиң түгел.

## № 36. Арча




Арча якларына карыйм
Дустым арча ягында. (2)
Арча ягы бигрәк матур,
Кош сайраган чагында.

Арчаларга [illegible]рсаң, бөгърем,
Ал гөлләрне өзәрсең;
Үзәгемне бик өзәсең,
Үзең ничек түзәсең?

## № 37. Кызыл, кызыл




Кызыл-кызыл бөрлегәннәр
Юл буена тезелгән;.
Булмас инде синең өчен
Минем кебек өзелгән.

Агыйделдән пароход килә,
Карагыз аклы кылларын.
Җырлап эчләрем бушатам,
Шул минем шатлыкларым.

## № 38. Уракчы кыз




Ай урагын салып иңбашына
Кояш нурларыннан нур алган;
Кояш нурларыннан нурлар алган,
Салкын чишмәләрдән су алган.

## № 39. Зәңгәр күлмәк




Зәңгәр күлмәгеңне киясең дә
Зәңгәр күлгә көн дә киләсең.
Йөрәгеңдә нинди утлар яна,
Уйларыңны килә беләсем.

Зәңгәр күлмәгеңне киясең дә
Яшел болыннардан үтәсең.
Болын чәчәкләрен җыя-җыя
Кемне болай сагынып көтәсең?

## № 40. Умырзая




Боз катлавы эрегәч җир өстенә
Умырзая чыга, карагыз.
Умырзая чыга, умырзая калка,
Умырзая суза сабагын.

Их мин яшәр идем җәй буена
Зур чәчәкләр белән бергәләп.
Их мин яшәр идем,
Их мин үлмәс идем,
Умырзая кебек моңаеп.

## № 41. Авыл көе




Җырлыйк әле, җырлыйк әле
Сызылып таңнар атса да, шул,
Сызылып таңнар атса да.
Үткән гомер кире кайтмый
Сулар үргә, лә, акса да.
Сандугачның мескенкәйнең
Канаты каерылган, шул,
Канаты каерылган.
Бер без генә түгел әле
Иләрдән аерылган.

## № 42а. Галиябану




Ак укага энҗе тездем,
Бер бөртеге калганчы;
Озатканда карап калдым,
Ак теләкләр тели-тели,
Күз керфегем талганчы.

Таң әтәчләре кычкыра,
Аерылуның билгесе;
Бу бүләгем, сиңе сөеп
Чын күңелемнән кайнап чыккан
Вәгъдәләрнең билгесе.

## № 42б. Галиябану




Тәрәзә төбем каты бал,
Ашыйсың килсә ватып ал;
Сөюләрең дөрес булса,
Галиябану, сылуым, иркәм,
Тәрәзәдән тартып ал.

## № 42б. Галиябану




Тәрәзәдән карыйсың, ла,
Карап кемне таныйсың?
Карап күзең талдырганчы,
Галиябану, сылуым, иркәм,
Ник чакырып алмыйсың?

## № 42г. Галиябану




Атлар килә атлап-атлап,
Алма чәчәген таптап.
Син дусларны күрәм дисәм,
Галиябану, сылуым, иркәм,
Турыда таулар каплап.

Ике аккош очып килә,
Берсе төште суларга.
Мәңге бергә булмагач та,
Галиябану, сылуым, иркәм,
Без охшыйбыз шуларга.

## № 43а. Саубуллашу көе




Туры атларга килешә
Кулдан үргән дилбегәй, шул;
Кычкырып җырлап җибәр идем,
Тавышым калсын билгегә.

## № 43б. Авыл көе




Сикердем читәннәрен, лә,
Йөгердем, җитә алмадым.
Ни булды икән телләремә,
Сау бул, дип, әйтә алмадым.

Урманнарны узган чакта
Адаштым юлларымны.
Күңелем йомшак, җырлармын, дип,
Бирмәдем кулларымны.

Өй артындагы талыңны
Яратмасаң кисәрсең, лә,
Мин сагынсам тәрәз ачам,
Син җил булып исәрсең.

## № 43в. Авыл көе




Биек, биек, эй таулардан
Күренә безнең туган ил;
Ямьле булса да торган җир,
Сагындыра туган ил.

И туган ил, и матур ил,
Калдың бездән еракта.
Калсан да бездән еракта
Күңелдә син һәр чакта.

Яшьлегемдә күкрәгемә
Чәчкәләр кадамадым.
Чөнки яшьлегемнән матур
Чәчкәне табалмадым.

## № 43г. Ялгыз каен




Ялгыз каен үсми диләр,
Ялгыз каен кулларда, шул,
Ялгыз каен динәдә дә ялгыз
Мин хәзерге көннәрдә.

Килә ява, килә ява,
Һавадагы бер болыт, шул,
Алда, ла, бәхетем булса иде,
Теләгем кабул булыр.

7–716

## № 44а. Минзәлә




Барасызмы Минзәләгә,,
Мин барам Минзәләгә, шул,
Минзәләне күрер өчен
Йөрәгем өзгәләнә.
Минзәләгә барганым юк,
Юллары такыр, диләр.
Такыр юлда йөреп үскән
Кызлары матур, диләр.

## № 44б. Авыл көе




Сандугачлар сайрамыйлар,
Телләрем тала, диеп, шул.
Алма да әйтә өзелеп төшкәч,
Агачым кала, диеп.

Абау, алла, башым авыра,
Мендәр салучылар юк.
Утка салучылар күп —
Тартып алучылар юк.

Алмалары, хөрмәләре
Кызарып пешәр әле.
Әле исенә төшмәсә дә
Соңыннан төшәр әле.

## № 45а. Сарман




Сандугачлар гына кайларда сайрый,
Сарман буйларында, тирәктә, шул, (2)
Сиңа булган яшьлек мәхәббәте
Үрелеп чәчәк ата, ла, еракта.

## № 45б. Сарман




Сарман буйларында яшел алан,
Печәннәре җитәр бер заман.
Бергә булулары бик күңелле,
Һәммә аерылышуы бик яман.

Сарман буйларына барган чакта
Тыңларсыңмы, җырлар җырлармын,
Күзләреңне тутырып карарсыңмы,
Таудан зәңгәр яулык болгармын.

## № 45в. Сарман




Сарман буйларында бик күп йөрдем,
Сарман суын эчеп туймадым, ла,
Сарман суын эчеп туймадым.
Әйтәр сүзләремне әйт'алмадым,
Тагыда күрешәрбез дип уйладым.
Әйтәр сүзләремне әйт'алмадым.
Тагыда күрешәрбез дип, уйладым.

## № 45г. Сарман




Сарман буйкайлары киртләч-киртләч,
Киртләчләре бетәр яз җиткәч дә, шул,
Киртләчләре бетәр яз җиткәч.
Ир баласы кайта хезмәт иткәч,
Кыз баласы кайтмый, бер киткәч.

## № 46а. Нурия




Башымдагы эшләпәмне
Элеп куйдым киртәгә.
Кичә дә кич килми калдың, Нурия,
Килми калма иртәгә.

Өстеңдәге күлмәгеңнең
Якаларын кем уйган?
Исмең матур, кемнәр куйган, Нурия,
Сине күреп кем туйган?

## № 46б. Нурия




Алмалары, хөрмәләре
Буялмасын күмергә.
Син онытсаң онытарсың, Нурия,
Мин онытмам гомергә.

Алма бакчасында үзем,
Гөл бакчасында күзем.
Язык түгел сөйләшеп тә, Нурия,
Бетәрлек түгел сүзем.

Ал гөлләре арасында
Сирень гөлләрем дә бар.
Бу дөньяга нигә тудым, Нурия,
Дигән кемнәрем дә бар.

## № 47. Илкәй




Сагынам, дуслар, сагынам, дуслар,
Сагынам, дуслар, илкәйне, шул,
Сагынам, дуслар илкәйне.
Илкәй белән бергә сагынам
Яшьләй сөйгән иркәмне.

## № 48а. Каз канаты




Каз канаты каләм була
Язу белгән кешегә.
Ниләр килеп ниләр китми
Дөнья көткән кешегә.

Каз канаты каурый-каурый,
Сәлам язырга ярый.
Уйнамагач та көлмәгәч
Бу дөнья нигә ярый.

Тәрәзә төбем чын кара,
Каз канаты каләмем.
Иртәңге җил кичкә салкын;
Минем сезгә сәламем.

## № 48б. Каз канаты




Каз канаты кат-кат була,
Ир канаты ат була.
Чит илләрдә бик күп йөрсәң,
Туганнарың ят була.

## № 48в. Каз канаты




Каз канатлырын санадым
Тезелеп кагынганда.
Инде кемнәргә карармын
Өзелеп сагынганда.

## № 49. Вәгъдә




Вәгъдә биргәч кирәк иде көтәргә,
Нигә инде хыянәт итәргә?
Янган идем, көйгән идем,
Өзелеп-өзелеп сөйгән идем
Шат тормышта гөрләп яшәргә.

Язгы төндә ачы җилләр истеләр,
Болынларда чәчәкләре тондылар.
Януларым,көюләрем,
Өзелеп-өзелеп сөюләрем —
Барысы да бушка уздылар.

Миндә кайгы, миндә хәсрәт, моңланам,
Кайгы хәсрәт ут эчендә мин янам.
Яшь йөрәгем, син ярсыма,
Давылдансоң диңгез тына,
Хәсрәтләрем бетәр бер заман.

## № 50. Хатлар язам




Хатлар язам мин сиңа
Мәскәү калаларына.
Әгәр, иркәм, тиз килмәсәң
Үзем барам яныңа.

Тәрәзә төбем исле гөл,
Сал да балдагыңны эл.
Сагынмагач, хат язмыйлар,
Сагынганны шуннан бел.

## № 51. Рәйхан




Өстеңдәге күлмәгеңнең
Якаларын кем уйган?
Әй, Рәйхан, исмең кемнәр куйган,
Сине күреп кем туйган?

## № 52. Чугачак көе




Хәятемне алтын йөзек дисәм,
Анын кашы матур энҗем син.
Бөтен дөнья алсын син мәләктән
Матурлыкның гүзәл өлгесен.

Айнын якты матур кичәсендә
Чылтырап аккан суны буйладым.
Киләчәктә бергә булырбыз, дип,
Шунда гына сине уйладым.

Иркәм, син булырсың зәңгәр чәчәк,
Мин булырмын зәңгәр күбәләк.
Иркәм, бәгыркәем, өсләрендә
Кунгаларпмын сөеп-иркәләп.

Хәятемнең алтын менбәренә
Әллә нинди моңлы кош кунган.
Аның моңы нечкә тамыр буйлап
Сызылып төшә хатка уң кулдан.

Тибрәткәндәй булып яшь йөрәкне
Тарткан чакта авырсын җырын;
Түзәлмичә акрын җырлый башлыйм
Җан әрнеткеч моңлы бер җырын.

Иркәм, сине генә уйлый-уйлый
Бетте чәчем минем коелып;
Синең өчен түккән күз яшемә
Калды анда кошлар коенып.

## № 53. Яңа тәфтиләү




И мөкаддәс моңлы сазым! Уйнадың син ник бик аз?
Син сынасың, мин сүнәмен, айрылабыз, ахрысы!

8–716

Күпме моңлансам кунып милли агачлар өстенә,
Барсы корган — бер генә юк җанлысы, яфраклы.

Очты дөнья читлегеннән тарсынып күңлем кошы,
Шат яратса да, җиһанга ят яраткан раббысы.

## № 54. Сагыш җыры




Иртә торып тышка чыксам -
Бер кызыл гөл ачылган;
Бу җирләргә килмәс идем,
Ризыкларым чәчелгән.

Ай яктысы, яктысы, ла,
Көн яктысы, яктысы.
Кай илләрдә йөри икән
Йөрәгемнең яртысы?

Ай яктысы якты диеп,
Ташка басып су алма;
Сөйгән ярың читтә диеп,
Ятлар белән чуалма.

Айга кара, айга кара,
Мин дә айга карармын.
Күз нурларың айга төшсә
Айдан эзләп табармын.

# IV. Кыска көйләр

## № 55. Җырлыйк әле




Җырлыйк әле, җырлыйк әле,
Җырламый тормыйк әле.
Мәҗлесләр күңелле булсын,
Җырлап утырыйк әле.

Җырлыйк әле, җырлыйк әле,
Җырламый тормыйк әле.
Инде калган гомерләрне
Җырлап уздырыйк әле.

Җырлыйк әле, җырлыйк әле
Уникегә тулганчы,
Уникеләргә тулганчы,
Дуслар күңеле булганчы.

Җырлыйк әле, җырлыйк әле,
Җырлыйк әле, иптәшләр.
Иптәшләр үзебезнеке,
Бәлки, гаеп итмәсләр.

## № 56. Бию көе




Биик әле, биик әле,
Биегән кеше бай була.
Биегән кеше бай булса да
Кесә чагы сай була.
Әйтерәбез түгелме,
Сиптерәбез түгелме,
Әйтергәннәр, сиптергәннәр
Без үзебез түгелме?

## № 57. Бию көе




Дуслар алма, дуслар хөрмә,
Дуслар кура җиләге.
Әй, дустым, кил әле,
Икәү әйләник әле.
Ашап-эчеп, уйнап көлик,
Бетмәс дөнья кирәге.
Эй, дустым, кил әле,
Икәү әйләник әле.

## № 58. Туй җыры




Ай, икегез, икегез,
Икегезнең битегез.
Икегез дә пар килгәнсез,
Тигез гомер итегез.

Икәү бергә утырасыз,
Бергә булсын уегыз.
Икегез дә пар килгәнсез,
Котлы булсын туегыз.

Пар күгәрчен дай гөрләшеп
Яшәгез бергә-бергә.
Икегез дә пар килгәнсез,
Аерылмагыз гомергә.

Пар былбыллар кавышкандай,
Ничек кавыштыгыз сез?
Икегез дә пар килгәнсез,
Ничек табыштыгыз сез?

Алтын йөзле, көмеш тешле,
Балалар үстерегез.
Безнең илгә лачын кебек
Батыр-уллар бирегез.

## № 59. Әпипә




Бас, кызым, Әпипә,
Син басмасаң, мин басам.
Актык Әпипә туенда
Басып калыйм, ичмасам.

Сикереп бар, сикереп бар,
Сындыр идән тактасын.
Сындырсаң идән тактасын,
Үзем түлим а[illegible]часын.

Бас, кызым, бас әле,
Тагы басарбыз әле;
Өстәлләргә кызыл җәеп
Туйлар ясарбыз әле.

Бас эзенә генә,
Кара күзенә генә.
Карасаң күзенә генә
Булыр үзеңә генә.

Кара, кара, карагыз,
Ни кылана балагыз.
Бер басуда бишне баса,
Басуларын санагыз.

## № 60. Фәрхәнә




Бары көйләрнең арасында
Фәрхәнәне яратам. (2)
Фәрхәнәне бер җырласам,
Бар хәсрәтен таратам.

Уйна, Барый, гармуныңны
Фәрхәнә көйләренә.
Көйләре ерактан килә
Барыйның өйләренә.

## № 61. Урам көе




Китәм дисең, китәм дисең,
Син бер китәрсең әле, ди,
Син бер китеп башларымны
Вайран итәрсең әле.
Кулымдагы балдагымның
Исемнәре Идрис.
Ничек бәгърем дип әйтим,
Җиде ятлар сөйдең иш.
Ничек бәгърем дип әйтим,
Җиде ятлар сөйдең иш.
Иркәм дидең, өзелеп сөйдем,
Ул вакытта тиң идем.
Өсләреңнән яклап сөйдем,
Мин кемнәрдән ким идем.
Өсләреңнән яклап сөйдем,
Мин кемнәрдән ким идем.
Кулымдагы балдагымның
Исемнәре Ләбибә.
Салкын карыйсың, җанашым,
Җаннарың теләмиме.
Салкын карыйсың, җанашым
Җаннарың теләмиме.

## № 62а. Баламишкин




Чыңгырлауның урамы, да,
Урамында бураны;
Чыңгырлауның урамында
Җыр җырламый буламы?

Бездә кызлар такмак әйтә
Баламишкин көенә.
Ачуланса кайтып китә
Әтисенең өенә.

Зимагорлар толчокта, да
Кайгырмыйлар мал юкка.
Кайгырсалар кайгыралар
Төмәкеләре юкка.

Алай итәрбез әле,
Болай итәрбез әле.
Җил ягына салам өеп
Дөнья көтәрбез әле.

## № 62б. Баламишкин




Җырла, җырла дип әйтәсез,
Җырчы егет мин түгел;
Кычкырып җырлап җибәрсәм
Җырчылардан ким түгел.

Бишмәтемдә биш төймә,
Алтынчысы каптырма.
Ни бар җырымны җырладым,
Тагы җырлар таптырма.

Уйсу җирдә, уйсу җирдә,
Уйсу җирдә су була.
Яшь вакытта уйна да көл,
Картайгач ул соң була.

Әйттем, дустым, дөресен,
Син оҗмахка керерсең.
Син оҗмахка кермәсәң дә
Тирәсендә йөрерсең.

## № 62в. Баламишкин




Жырла, жырла, дип әйтәсез,
Жырламыйсыз үзегез,
Яндырадыр, көйдерәдер
Жырла дигән сүзегез.

Апыр-топыр куйлар килә,
Арасында бер кара;
Акылың булса, уйлап кара:
Бу дөньяда кем кала.

## № 62г. Баламишкин



Җырлыйк әле, җырлыйк әле,
Уникегә тулганчы.
Уникегә, ай, тулганчы,
Дуслар күңеле булганчы.

Утырмыйча булмас инде
Алма коелган җиргә.
Җырламыйча булмас иде
Дуслар җиелган җирдә.

Җырлыйм әле, җырлыйм әле,
Берне түгел, әй, өчне.
Җырламас идем, әй, өчне,
Әйткән сүзегез көчле.

## № 62д. Баламски




Җырла дигез, мин җырлаймын,
Бер сүзеңне тыңлайып.
Мин әйткәндә син дә тыңла,
Мин дә мәхрүм булмайым.
Җырла, җырла, дип әйтәсез,
Җыр чәчмәдем бакчага,
Җыр чәчмәдем дә бакчага,
Сатып алмыйм акчага.

9-716

## № 62е. Баламски




Ал бидерә, гөл бидерә,
Күзләрне чагылдыра;
Бергә чакта берни түгел,
Аерылгач сагындыра.

Әй, дисеннәр, дисеннәр,
Болар кемнәр, дисеннәр.
Болар кемнәр дип сораса,
Бер туганнар, дисеннәр.

## № 62ж. Петропавыл такмаклары



Петропавыл чибәр кала,
Манарага менеп карасаң.
Яшел калфаклар килешә,
Чәчең майлап тарасаң.

Петропавыл каласы,
Бишкүл аның даласы.
Аша да эч, уйна да көл,
Фани дөнья бездән каласы.

Петропавыл матур кала
Ишел суы буенда.
Уйнап-көлеп утырабыз
Галиянең туенда.

Петропавыл каласында
Алты мәчет, биш чиркәү.
Ялгыз җырлаулары авыр,
Кода, җырлашик икәү.

Бишкүл буе, Бишкүл буе,
Бишкүл буе була ул.
Әйтче миңа, дустыкаем,
Кем исемле була ул?

Бишкүл буе урманында
Акырам да бакырам.
Үзем белән җырлашырга,
Кода, сезне чакырам.

Баламишкинның атлары
Сызгармыйча су эчми;
Петропавылның кызлары
Җырламыйча чәй эчми.

## № 62з. Баламски көенә






Эй, дусларым, сезнең белән
Күтәреләә күңелләр.
Күтәрелгән күңел белән
Үтсен безнең гомерләр.

Ой, дусларым, дусларым,
Дусларым, дус-ишләрем.
Сез дуслардан аерылсам,
Ялгыз башым нишләрмен?

Алмагачы чәчәк ата
Майның унбишләрендә.
Былбыл булып, гөлгә кунып
Керәсез төшләремә.

## № 63. Күзләрең




Күзләреңне, күзләреңне,
Күрмәгән булсам иде.
Сөям дигән сүзләреңне
Ишетмәгән булсам иде.

Күзләреңдә магнит бармы?
Талдыра күзләремне.
Сүзләреңдә ялкын бармы?
Яндыра йөрәгемне.

Ак куянга әйтегезче,
Ак чәчәкне өзмәсен,
Минем иркәмә әйтегезче,
Өметләрен өзмәсен.

Күзләрең кара чия,
Җандарым сине сөя,
Җанларым сине сөйгәнгә
Дошманнар яна-көя.

Күзләреңне,күзләреңне
Айлы кичтә күзләдем.
Синең эчке серләреңне
Күзләреңнән эзләдем.

Күзләремне, күзләремне,
Күзләремне күзләмә.
Минем күзем төпсез диңгез —
Аннан серләр эзләмә.

## № 64. Айхайлук




Бер көн төндә бер төш күрдем:
Акбуз атка атландым.
Айхайлук!
Ай, ли, Гыйзелбану, күлмәгең.
Кичә көндез кайда булдың,
Нурлы йөзең күрмәдем.

Күргән төшем кабул булды,
Сине күреп шатландым.
Айхайлук!
Ай, ли, Гыйзелбану, шәлләрең.
Кичә көндез күрәлмадым,
Ничек икән хәлләрең?

Яшь вакытта күкрәгемә
Чәчәкләр кадалмадым.
Айхайлук!
Ай, ли, Гыйзелбану, яулыгың.
Кичә көндез күрәлмадым,
Ничек икән саулыгың?

Чөнки яшьлектән дә матур
Чәчәкләр табалмадым.
Айхайлук!
Ай,ли, Гыйзелбану,чабатаң.
Җиен дуслар арасында
Сине генә яратам.

## № 65. Күбәләк




Тау астында, тал астында
Салкын чишмә түгәрәк.
Очып, барып килер идем,
Күбәләгем, түгәрәгем,
Асыл кошым, сандугачым,
Әгәр булсам күбәләк.

## № 66. Сәрия




Әнә килә автомобиль, Сәрия,
Тиягәннәр таш-күмер, Сәрия,
Әкрен генә сиздермичә,
Сандугач баласы, ла,
Әкрен генә сиздермичә
Үтә безнең яшь гомер.

Йөгерә-йөгерә җитәлмим, Сәрия,
Тал чыбыктан үтәлмим, Сәрия,
Тал чыбыктан үтәр идем,
Сандугач баласы, ла,
Сезне ташлап китәлмим, шул,
Сезне ташлап китәлмим.

## № 67. Талы, талы



Тәрәзә төбем исле гөл,
Иснә дустым, исле ул.
Уртасында бер чәчәк бар,
Өзмим, синең төсле ул.
Талы, талы,
Талы бөгелеп тора.
Тагын бер күрәсем килеп,
Үзәк өзелеп тора.

Тәрәзә төбем исле гөл,
Куна микән күбәләк?
Бергә чакта уйнап-көлеп
Яшик, дуслар, бергәләп.
Талы, талы,
Талы бөгелеп тора.
Тагын бер күрәсем килеп,
Үзәк өзелеп тора.

Тәрәзә төбем исле гөл,
Рәхәтләнәм исенә,
Сәгать саен, минут саен
Син төшәсең исемә.
Талы, талы,
Талы бөгелеп тора.
Тагын бер күрәсем килеп,
Үзәк өзелеп тора.

## № 68. Йолдызым, рушаным




Үзләренең коесы бар,
Безгә килеп су ала.
Чиләген тутырып ала да
Көлә-көлә югала.
Ай, йолдызым, йолдызым,
Йолдызым, рушаным.
Син кергән гөл бакчасына
Керергә тырышамын.

Сандугачлар су дип эчә
Урмандагы чыкларны.
Уйлыйсыңмы сагынасыңмы,
Бергә булган чакларны?
Ай, йолдызым, йолдызым,
Йолдызым, рушаным.
Син кергән гөл бакчасына
Керергә тырышамын.

## № 69. Җизнәкәй




— Ул йөзләрең ник саргайган, җизнәкәй?
— Сине өзелеп сөйгәнгә, балдызым, ялгызым.

— Ул бармагың ник кәкре, җизнәкәй?
— Алтын йөзек кигәнгә, балдызым, ялгызым.

— Аякларың ник кәкре, җизнәкәй?
— Читек-кәвеш кигәнгә, балдызым, ялгызым.

— Балдыз сөю язык диләр, җизнәкәй.
— Язык казык башында, балдызым, ялгызым.

## № 70. Чибәр егет




— Чибәр егет килгән чакта
Чаең бармы әнкәем?
— Чәем түгел, ашым хәзер,
Уфаланма, бәбкәем.

— Чибәр егет килгән чакта
Чаршау бармы, әнкәем?
— Чаршау түгел, түшәк хәзер,
Уфаланма, бәбкәем.

— Чибәр егет килгән чакта
Су хәзерме, әнкәем?
— Суым түгел, мунчам әзер,
Уфаланма, бәбкәем.

— Чибәр егет килгән чакта
Нишлим икән, әнкәем?
— Чибәр егет үзе белә,
Тик кенә тор, бәбкәем.

# V. Авторлык җырлар

## № 71. Тәуге сөю

Г.Таминдаров көе
Р.Гузаиров шигыре




Агым сулар агар инде,
Ярларына сыймыйча.
Яшь гомерләр узар инде,
Чын йөрәктән сөймичә.

Төшләремдә күргән кебек
Яшьлегемнең хисләре.
Колагымда һаман чыңлый
Сөям дигән сүзләре.

Яшел үләннәр каплады
Балачак сукмакларын.
Тик йөрәгем иң түрендә
Сине генә саклады.

Шул сукмакларда калдылар
Ялан-аяк эзләрем.
Килер сыман ераклардан
Тәуге сөю хисләрем.

## № 72. Ашкынам мин туган ягыма

Г.Таминдаров көе
Р.Гузаиров шигыре

Lento




Ничә айлар, ничә еллар,
Ашкынам туган илгә.
Белмим нигә язмышларым
Кайтармый туган җиргә.

Кайтсам иде үз ягыма
Алсу таңнар атканда.
Кошлар моңын тыңлар идем,
Тугай буйлап кайтканда.

Ялан-аяк йөрер идем
Чирәмгә чык төшкәндә.
Йөрәкләрем янмас иде
Салкын суын эчкәндә.

Кошлар да бит җылы яктан
Әйләнеп кире кайта.
Кошлар булып, канат кагып
Кайтыйк без туган якка.

## № 73. Кар сулары

Г.Таминдаров көе
Р.Гузаиров шигыре

Lento




Эрегәндә ап-ак карлар,
Искә төшә Кызылъярлар.
Йөрәкләрдән китми һаман,
Яшьлектәге сөйгән ярлар.

Кар суларына карасам,
Сызыла йөрәк майларым.
Берсен-берсе куган кебек,
Үтә минем айларым.

Кар сулары алып китә
Безнең салган эзләрне.
Еллар аша сагындырып,
Матур кара күзләрне.

Кар сулары ташкын булып
Аксын туган илләргә.
Калган эзләрне югалтмый
Туып үскән җирләргә.

## № 74. Яшьлегемнең таңнары

Г.Таминдаров көе
Р.Гузаиров шигыре




Сандугачларны уята
Яшьлегемнең таңнары.
Сүнгән утларны яндыра
Тальян гармун моңнары.

*Кушымта:*

Хыялларым канатланып
Яшьлеккә алып китә.
Әкрен генә, сиздермичә
Яшь гомеркәйләр үтә.

Алсу таңнары аттыра
Сандугачкаем сайрап.
Канатларыңны талдырма
Кунар талыңны сайлап.

*Кушымта.*

Биек тауларның башында
Каеннар яфраксыз.
Бу дөньяда кошлар гына
Кайгысыз, хәсрәтсез.

*Кушымта.*

## № 75. Чабата

Г.Таминдаров көе
Р.Гузаиров шигыре




Аулакларда без биибез,
Көе килми димибез.
Бергә кайларга барсак та —
Аяктагы чабата.

*Кушымта:*
Чаба-чаба, чабата,
Биегәнне ярата.

Әткәем дә яшь чагында
Чабата киеп үскән.
Балачак сукмакларында
Эзен калдырып үткән.

*Кушымта.*

Чабата кийсәк тө дуслар,
Бай булсын безнең күңел.
Тормыш авырлыкларына
Бирешкәннәр без түгел.

*Кушымта.*

Сөям дигән сүзләреңне
Әллә ничә укыдым.
Сиңа бүләк итәр өчен
Мин чабата тукыдым.

*Кушымта:*
Чаба-чаба, чабата,
Биегәнне ярата.
Матур кызлар дөртле биеп
Үзләренә карата.

## № 76. Матур булсын киләчәк

Г.Таминдаров көе.
Р.Абдусалямов шигыре

Allegro




Бакчаларга мин кердем,
Матур чәчәкләр күрдем.

*Кушымта:*

Кызыл чәчәк, ал чәчәк,
Безнең матур киләчәк.

Кояш нурларын чәчә,
Бәхет нурларын ача.

*Кушымта.*

Биибез бергәләшәп,
Җырлыек без гөрләшәп.

*Кушымта.*

## № 77. Безнең «Сарман»

Г.Таминдаров көе
Р.Гузаиров шигыре

Allegretto




Алатаудан Балатауга
Китә «Сарман» моңнары.
Бергә җырлап, бергә бию —
Шул «Сарман»ның уйлары.

*Кушымта:*

Сайрат, сайрат гармуныңны,
Биесеннәр яшь кызлар.
Баскан җирдән ут чыгара
Безнең «Сарман» дисеннәр.

Ямьле Сарман буйларында
Сандугачлар сайрыйлар.
Матур кызлар уйларында
Белмим кемне сайлыйлар.

*Кушымта.*

Уйна, дустым, гармуныңны.
Биесен әле кызлар.
Йөрәкләрне җилкендерә
Безнең «Сарман» дисеннәр.

*Кушымта.*

Иркен казак даласында
Янгырый «Сарман» җырлары.
Бергә җырлап, бергә бию —
Шул «Сарман»ның уйлары.

*Кушымта.*

## № 78. Җилләр исә

Г.Таминдаров көе
Р.Гузаиров шигыре




Җилфер-җилфер җилләр исә
Безнең туган якларда.
Сагыну утларында янам
Сез булмаган чакларда.

Уйнап-көлеп күңел ача
Безнең авыл яшьләре.
Эштә уңган, җырда булган
Бигрәк матур үзләре.

Әле дә булса күз алдымда
Басулары-кырлары,
Еракларга киң таралган
Безнең халык җырлары.

Зәңгәр күктән очкан кошлар
Канатлары талмасын.
Яшьли сөю хисләребез
Үкенечкә калмасын.

## № 79. Бер яшьлектә, бер картлыкта...

Г.Таминдаров көе
Р.Гузаиров шигыре




Уңган була, матур була
Безнең якның кызлары.
Алматының алмасыдай
Балкып тора йөзләре.

Вак-вак атлап, йомшак басып
Бииләр безнең кызлар.
Күңел хисләрен яңгыратып
Килсеннәр матур язлар.

Кайда гына йөрсәмдә,
Уйларымда син генә.
Бер яшьлектә, бер картлыкта
Уйнап-көлгән без генә.

## № 80.Нурия

Г.Таминдаров көе
Р.Гузаиров шигыре

Allegretto




Нечкə билле Нуриякəй
Матур кулмəген кия.
Шул Нурия дия-дия
Егетлəр янып-көя.

Йөзлəрендə нурлар уйный,
Кыйгач кашлары кара.
Тал чыбыктай нечкə билле
Нурия суга бара.

Нурлы-назлы Нуриякəй
Ап-ак калфагын кия.
Барган чакта чишмəлəргə
Чəчкəлəр башын ия.

Алсу таңнар аткан чакта
Егетлəр йоклап ята.
Киянтəлəрен уйнатып
Нурия судан кайта.

# № 81. Сагынам

Г.Таминдаров көе
Р.Гузаиров шигыре

Allegro




Сагыңам туган якларның
Чишмәләрен, суларын.
Алсу таңнар аткан чакта
Сандугачлар сайравын.

Түбән очтан югарычка
Җырлашып үткәннәрне.
Озатканда сөйгәнемнең
Кочаклап үпкәннәрен.

Истә калган аулак өйләр,
Җырлаган да моңлы көйләр.
Гашыйкларның саф хисләре,
Чәчәкләрнең хуш исләре.

Колагымда һаман чыңлый
Җиз кыңгырау чыңнары.
Яшьлегемә чакыралар
Тальян гармун моңнары.

# № 82. Минем мәхәббәтем

Шәукәт Сагаутдинов көе
Шамил Сагаутдинов шигыре




Матур гөлне эзләп йөрдем
Чәчкәләр арасында.
Сине күргәч, матур гөлләр,
Чәчәк атты йөрәгемдә:

Синең якты күзләренә
Беренче караш салдым.
Шунда бергә булуыбызны
Гомерлеккә мин аңладым.

Сандугачым, әйтеп сайра
Мәхәббәт серләремне.
Үзем никтер каушап калам,
Әйтә алмыйм шул сүзләрне.

Әйтеп бир мәхәббәтемнең
Якты һәм пакь булуын.
Аңлатып бир күңелемнең
Бер аны гына уйлавын.

Карлыгачкаем минем син!
Бөтен күңелем синдә.
Минем кебек бәхетле җан
Юк бөтен дөнья йөзендә.

Күзләрем дә мәңге туймас
Күреп нурлы йөзеңне.
Алладан сораганым шул:
Аерма, Ходам, син безне.

## № 83. Мәхәббәт сүрелми

Ш.Сагаутдинов
көе һәм шигъре




Кыш үтте, яз килде,
Ага су ташкыны.
Су кебек, йөрәгем
Ашыга ашкынып.

*Кушымта:*

Синең якты йөзең
Күңелемне яндыра,
Нурлы күзләрең мине
Гел куандыра.

Яз үтте, җәй килде,
Җир йөзе ямьләнә.
Ә минем өчен ямь
Син генә, син генә.

*Кушымта.*

Җәй үтте, көз җитте,
Сибәли яңгырлар.
Тик алар йөрәкне
Сүндерә алмаслар.

*Кушымта.*

Гел яшәрбез шулай,
Гомеребез булса.
Мәхәббәт сүрелмәс
Һәм, Ходай боерса,

*Кушымта:*

Синең якты йөзең
Күңелемне яндырыр,
Нурлы күзләрең мине
Гел куандырыр.

## № 84. Язгы ташкын

Э.Гузаирова көе
Р.Гузаиров шигыре




Язгы ташкын кебек шаулап
Үтә яшьлек елларым.
Калышмыйлар дәрьяләрдән
Сагышларым-моңнарым.

*Кушымта:*

Дәрья суларын бергәләп
Нигә кичмәдек икән?
Мәхәббәтнең кадерләрен
Нигә белмәдек икән?

Тормыш дулкыннары безне
Ташлады төрле якка.
Йөрәкләрем һаман яна
Җаннарымда син юкка.

*Кушымта.*

## № 85. Ромашкалар

Э.Гузаирова көе
Муса Җәлил шигыренә




Иртәнге таң нурыннан
Уянды ромашкалар.
Елмаеп, хәл сорашып,
Күзгә-күз караштылар.

*Кушымта:*

Ап-ак күлмәк кигән кызга
Охшаган ромашкалар.
Әйтерсең дә туйда сыман —
Икесе дә чибәрләр.

Назлады җил аларны
Тибрәтеп ак чукларын,
Таң сипте өсләренә
Хуш исле саф чыкларын.

*Кушымта.*

## № 86. Көтәм сине

Э. Гузаирова
көе һәм шигыре




Көтәм өле сине,
Көтәм өметләнеп.
Куанычлы көн килер дип
Якты уй белән янам мин.

*Кушымта:*

Язлар көтәм мин,
Җәйләр көтәм мин.
Хатлар көтәм мин,
Мәхәббәтем килер дип.

Таңнар атса сызылып
Каеннарга карыйм мин.
Әллә нишли йөрәгем —
Мәхәббәтем кайтыр, ди.
*Кушымта.*

Кайтмадың бит син инде.
Ничә ел көттем сине.
Ялгызлыкта үтте
Минем гомер юлларым.
*Кушымта.*

# № 87. Алматы турында җыр

Э.Гузаирова көе
Р.Гузаиров шигыре




Якты йолдызлар җимелди
Алматының күгендә.
Мәңгелеккә сакланырсың
Йөрәгемнең түрендә.

*Кушымта:*

Сандугачларың да синең
Моңлы итеп сайрыйлар.
Күбәләкләр канат кагып
Матур гөлләр сайлыйлар.

Кайда гына йөрсәм дә -
Кире киләм мин сиңа.
Тауда аккан суларың да
Шифа булалар миңа.
*Кушымта.*

Ап-ак алма бакчаларың
Чәчәк ата майларда.
Тын кичләрең матурлана
Җәйге җылы айларда.
*Кушымта.*

Шатландырып киң ачылды
Безгә бәхет ишеге.
Тибрәндерсен туктамыйча
Дуслык — сәнгәт бишеге.
*Кушымта.*

## № 88. Үткән мәхәббәт

Э.Гузаирова көе
Р.Гузаиров шигыре




Кабат чыктың минем сукмагыма.
Беләгемне кыстың әкрен генә.
Туктап синең күзләренә карыйм,
Үткән мәхәббәтем хакына.

*Кушымта:*

Нигә киттең син
Ерак җирләргә?
Сине генә, сине генә,
Сине генә сөям мин.

Сабыр гына «сау бул» дидең миңа,
Башны идең дә киттең тын гына.
Үткән мәхәббәтең уйларымнан
Керфекләргә яшен тагыла.

*Кушымта.*

Җәйләр килде язлар артларыннан.
Кояш кебек, якты, җылы, нурлы.
Яшьлек иртәсендә очрадың да
Мәңгелеккә калдың күңелемдә.

*Кушымта.*

## № 89. Моңсу

Э.Гузаирова көе
Р.Гузаиров шигыре




Сандугачларны уята
Яшьлегемнең таңнары.
Сүнгән утларны яндыра
Тальян гармун моңнары.

*Кушымта:*

Хыялларым канатланып
Яшьлеккә алып китә.
Әкрен генә, сиздермичә
Яшь гомерләр үтә.

Алсу таңнары аттыра
Сандугачкаем сайрап.
Канатларыңны талдырма
Кунар талыңны сайлап.

*Кушымта.*

Биек тауларның башында
Каеннар яфраксыз.
Бу дөньяда кошлар гына
Кайгысыз, хәсрәтсез.

*Кушымта.*

# КОММЕНТАРИИ

**1. Аппагым, жанашым.** Записано от Л.З.Сермухамедовой (1937)[1] в г.Алматы. Характерный образец протяжного напева с богатой орнаментацией.

**2. Зөлхиҗҗә.** Зап. от Х.Х.Галиакберовой (1948) в г.Алматы. Старинная башкирская песня, получившая популярность в татарской среде. Данная песня имеется в сборнике А.В.Затаевича (ПРН[2], с.213, № 3).

**3а. Уел.** Зап. от Х.Х.Галиакберовой (1948) в г.Алматы. Протяжная песня, бытует с различными текстовыми вариантами. Данный вариант — наиболее распространенный. Песня также была зафиксирована А.В.Затаевичем в 30-е годы (ПРН, С.113, № 3).

**3б. Уел.** Зап. от М.Г.Хабибуллиной (1901) в г.Алматы. Упрощенный вариант, по стилю исполнения приближается к жанру «салмак».

**4. Гөлҗамал.** Зап. от Х.Х.Галиакберовой (1948) в г.Алматы.

**5. Тәфтиләү.** Зап. от Т.В.Бахтеевой (1947) в г.Петропавловске. Широко известная мелодия башкирской исторической песни, в татарском варианте получила распространение с текстом стихотворения Г.Тукая «Өзелгән өмет» («Разбитая надежда»). В сборнике А.В.Затаевича присутствует под названием «Махбус» («Заключенный») ПРН, с.114, № 11.

**6а. Зиләйлүк.** Зап. от С.Ш.Сабитовой (1927) в г.Петропавловске. Старинная протяжная песня, исполняемая обычно на текст стихотворения Г.Тукая. Данный вариант имеет некоторые стилистические отличия в сравнении с наиболее распространенными. (ПРН, с.127, № 43).

**6б. Зиләйлүк.** Зап. от М.Г.Хабибуллиной (1901) в г.Алматы.

**7. Һаваларда йолдыз.** Зап. От М.Г.Сиразитдиновой (1911) в г.Алматы. Протяжная песня с контрастным припевом. В сборнике А.В.Затаевича — под названием «Газизәкәй балдыз» (ПРН, с.118, № 21).

**8. Салкын чишмә.** Зап. от М.Г.Сиразитдиновой (1911) в г.Алматы. В записи А.В.Затаевича имеются два варианта (ПРН, с. 114, № 10 и с.123, № 32).

**9. Үкенү.** Зап. от М.Г.Сиразитдиновой (1911) в г.Алматы.

**10. Сәгать чылбыры.** Зап. от М.Г.Хабибуллиной (1901) в г.Алматы.

**11. Ашказар.** Зап. от М.Г.Хабибуллиной (1911) в г.Алматы. Старинная башкирская песня, рапространенная и в татарской среде.

**12а. Кара урман.** Зап. от М.Г.Сиразитдиновой (1911) в г.Алматы.

[1] В скобках указывается год рождения исполнителя.
[2] Сокр: Затаевич А.В. Песни разных народов. А-А.,1971.

Старинная протяжная песня лирического характера, весьма популярна у казахстанских татар. Существует в различных стилистических вариантах.

**12б. Кара урман.** Зап. от С.З.Сафитовой (1907) в г.Талгаре Алматинской обл.

**12в. Кара урман.** Зап. от Р.Х.Сеитовой (1933) в г.Семипалатинске.

**12г. Кара урман.** Зап. от М.Б.Валиуллиной (1922) в с.Беленское Угловского р-на Алтайского края. Данное село находится вблизи г.Семипалатинска, на границе с Казахстаном. Исполнительница — казашка по национальности.

**13. Карурман аша.** Зап. от З.Р.Табаевой (1940) в г.Алматы.

**14а. Сак-Сок.** Зап. от Х.Ш.Зайнуллиной (1922) в г.Семипалатинске.

**14б. Сак-Сок.** Зап. от Х.Ш.Зайнуллиной (1822) в с.Беленское (см.комм. к № 12г).

**15а. Сак-Сок.** Зап. от Ш.Г.Темирбулатовой (1934) в г.Мамлютка, СКО. Второй вариант мелодического сопровождения баита. Широко распространившаяся в татарской песенной культуре в качестве «баитной» мелодия песни «Хас-Булат».

**15б. Сак-Сок.** Зап. от Б.Г.Сабитовой (1932г.) в г.Семипалатинске.

**15в. Сак-Сок.** Зап. от Л.З.Сермухамедовой (1937) в г.Алматы.

**16. Ямщик бәете.** Зап. от Х.К.Именовой (1925) в с.Беленское (см. комм. к № 12г). Свободный перевод русской песни «Степь да степь кругом».

**17. Кара син алга.** Зап. от Х.Ш.Зайнуллиной (см. комм. к № 14б).

**18а. Суга баткан Гайшә.** Зап. от М.Г.Сиразитдиновой (1911) в г.Алматы.

**18б.** Суга **баткан Гайшә.** Зап. от З.Р.Табаевой (1940) в г.Алматы. Вариант по стилистике приближен к лирической песне.

**18в. Суга баткан Гайшә.** Зап. от Л.З.Сермухамедовой (1937) в г.Алматы. Тот же баит, исполнен на значительно упрощенную мелодию песни «Туган тел».

**19. Әткәемне кәтәм әле.** Зап. от Л.З.Сермухамедовой. Баит на военную тематику. Характерный для современного исполнительства случай использования известных мелодий лирических песен. Здесь используется мелодия популярной песни «Кошлар». (См. № 25).

**20. Уза яшь гомер.** Зап. от Х.Ш.Зайнуллиной (1922) в с.Беленское (см. комм. к № 12г).

**21. Солдат бәете.** Зап. от А.А.Тазетдинова (1929) в г.Алматы.

**22. Мөнәҗәт.** Зап. от З.К.Адигановой (1936) в г.Алматы.

**23. Мөнәҗәт.** Зап. от З.К.Адигановой (1936) в г.Алматы.

**24. Бишкүл.** Зап. от А.А.Нуриахметовой (1940) и Г.Н.Даутовой (1938) в г.Петропавловске.

**25а. Кошлар.** Зап. от Р.А.Узбековой (1935) в г.Мамлютка СКО.

12-716

Старинная протяжная песня лирического характера, весьма популярна у казахстанских татар. Существует в различных стилистических вариантах.

**12б. Кара урман.** Зап. от С.З.Сафитовой (1907) в г.Талгаре Алматинской обл.

**12в. Кара урман.** Зап. от Р.Х.Сеитовой (1933) в г.Семипалатинске.

**12г. Кара урман.** Зап. от М.Б.Валиуллиной (1922) в с.Беленское Угловского р-на Алтайского края. Данное село находится вблизи г.Семипалатинска, на границе с Казахстаном. Исполнительница — казашка по национальности.

**13. Карурман аша.** Зап. от З.Р.Табаевой (1940) в г.Алматы.

**14а. Сак-Сок.** Зап. от Х.Ш.Зайнуллиной (1922) в г.Семипалатинске.

**14б. Сак-Сок.** Зап. от Х.Ш.Зайнуллиной (1822) в с.Беленское (см.комм. к № 12г).

**15а. Сак-Сок.** Зап. от Ш.Г.Темирбулатовой (1934) в г.Мамлютка, СКО. Второй вариант мелодического сопровождения баита. Широко распространившаяся в татарской песенной культуре в качестве «баитной» мелодия песни «Хас-Булат».

**15б. Сак-Сок.** Зап. от Б.Г.Сабитовой (1932г.) в г.Семипалатинске.

**15в. Сак-Сок.** Зап. от Л.З.Сермухамедовой (1937) в г.Алматы.

**16. Ямщик бәете.** Зап. от Х.К.Именовой (1925) в с.Беленское (см. комм. к № 12г). Свободный перевод русской песни «Степь да степь кругом».

**17. Кара син алга.** Зап. от Х.Ш.Зайнуллиной (см. комм. к № 14б).

**18а. Суга баткан Гайшә.** Зап. от М.Г.Сиразитдиновой (1911) в г.Алматы.

**18б.** Суга **баткан Гайшә.** Зап. от З.Р.Табаевой (1940) в г.Алматы. Вариант по стилистике приближен к лирической песне.

**18в. Суга баткан Гайшә.** Зап. от Л.З.Сермухамедовой (1937) в г.Алматы. Тот же баит, исполнен на значительно упрощенную мелодию песни «Туган тел».

**19. Әткәемне котәм әле.** Зап. от Л.З.Сермухамедовой. Баит на военную тематику. Характерный для современного исполнительства случай использования известных мелодий лирических песен. Здесь используется мелодия популярной песни «Кошлар». (См. № 25).

**20. Уза яшь гомер.** Зап. от Х.Ш.Зайнуллиной (1922) в с.Беленское (см. комм. к № 12г).

**21. Солдат бәете.** Зап. от А.А.Тазетдинова (1929) в г.Алматы.

**22. Мөнәҗәт.** Зап. от З.К.Адигановой (1936) в г.Алматы.

**23. Мөнәҗәт.** Зап. от З.К.Адигановой (1936) в г.Алматы.

**24. Бишкүл.** Зап. от А.А.Нуриахметовой (1940) и Г.Н.Даутовой (1938) в г.Петропавловске.

**25а. Кошлар.** Зап. от Р.А.Узбековой (1935) в г.Мамлютка СКО.

**42г. Галиябану.** Зап. от С.А.Алибаевой (1933) в г.Капчагае Алматинской области.

**43а. Саубуллашу көе.** Зап. от С.Даурановой (1924) в г.Алматы.

**43б. Авыл көе.** Записано от З.Л.Гумаровой (1914) в г.Мамлютка СКО.

**43в. Авыл көе.** Зап. от А.А.Тазетдинова (1929) в г.Алматы.

**43г. Ялгыз каен.** Зап. от М.Ф.Абдрашитовой (1929) в с.Беленское (см. комм. к № 12г).

**44а. Минзәлә.** Зап. от М.Н.Умяровой (1943) в г.Шымкенте.

**44б. Авыл көе.** Зап. от А.Г.Идрисова (1917) в г.Петропавловске.

**45а. Сарман.** Зап. от В.Г.Сабитовой (1932) в г.Семипалатинске. Одна из самых любимых и почитаемых песен среди татар Южного и Восточного Казахстана. Популярна и в казахской среде (см. №№ 45б, 45в).

**45б. Сарман.** Зап. от С.А.Алибаевой (1933) в г.Капчагае Алматинской области.

**45в. Сарман.** Зап. от М.Б.Валиуллиной (см. комм. к № 12г).

**45г. Сарман.** Зап. от Ф.М.Валеевой (1927) в г. Капчагае Алматинской области.

**46а. Нурия.** Зап. от Х.Х.Галиакберовой (1948) в г.Алматы.

**46б. Нурия.** Зап. от М.Ф.Абдрашитовой (1929) в с.Беленское (см. комм. к № 12г).

**47. Илкөй.** Зап. от Х.Х.Галиакберовой (1948) в г.Алматы.

**48а. Каз канаты.** Зап. от М.Г.Сиразитдиновой (1911) в г.Алматы (ПРН, с.112, № 6).

**48б. Каз канаты.** Зап. от Н.Х.Габитовой (1918) и Б.Г.Габитовой (1917) в с.Беленское (см. комм. к № 12г).

**48в. Каз канаты.** Зап. от С.С.Нугаевой (1920) в г.Уральске.

**49. Вәгъдә.** Зап. от Л.З.Сермухамедовой (1937) в г.Алматы.

**50. Хатлар язам.** Зап. от Ф.М.Валеевой (1927) в г.Капчагае Алматинской области.

**51. Рәйхан.** Зап. от М.Г.Сиразитдиновой (1911) в г.Алматы.

**52. Чугачак көе.** Зап. от Ф.Г.Байчуриной (1918) в г.Алматы. Чугачак — город в КНР. Песня представляет собой образец нового фольклора, распространилась в среде татар, живших на территории Китая.

**53. Яңа тәфтиләү.** Зап. от З.Р.Табаевой (1940) в г.Алматы. Название старинного башкирского напева (см. комм. к № 5) перенесено на новую мелодию, исполняемую с текстом стихотворения Г.Тукая.

**54. Сагыш җыры.** Зап. от З.Р.Табаевой (1940) в г.Алматы. Образец заимствования мелодии популярного ранее романса «Кари глазки». В Казахстане более известен «казахский» вариант на стихи Абая «Айттым сәлем, Қаламқас».

**55. Җырлыйк әле.** Зап. от М.Г.Сиразитдиновой (1911) в г.Алматы.

**56. Бию көе.** Зап. от Б.Г.Сабитовой (1932) в г.Семипалатинске.

**57. Бию көе.** Зап. от Ф.М.Валеевой (1927) в г.Капчагае Алматинской области.

**58. Туй җыры.** Зап. от Б.Г.Сабитовой (1932) в г.Семипалатинске.

**59. Әпипә.** Зап. от Х.А.Шагвалеевой (1909) в г.Мамлютка СКО.

**60. Фәрхенә.** Зап. от Х.А.Шагвалеевой.

**61. Урам көе.** Зап. от Л.З.Сермухамедовой (1937) в г.Алматы.

**62а. Баламишкин.** Зап. от Л.В.Монасыповой (1931) и Л.В.Хисамовой (1933) в селе Чингирлау Уральской области. Одна из самых «универсальных» мелодий, популярна во всех регионах Казахстана. Существует в различных формах исполнения: в качестве плясовой, «частушечной», сопровождает песенные диалоги и т.д. (ПРН, с.134, № 60).

**62б. Баламишкин.** Зап. от С.С.Нугаевой (1920) в г.Уральске.

**62в. Баламишкин.** Зап. от С.А.Алибаевой (1933) в г.Капчагае Алматинской области.

**62г. Баламишкин.** Зап. от Ф.Г.Байчуриной (1918) в г.Алматы.

**62д. Баламски.** Зап. от Б.Г.Сабитовой (1932) в г.Семипалатинске.

**62е. Баламски.** Зап. от Б.Г.Сабитовой (1932) в г.Семипалатинске.

**62ж. Петропавыл такмаклары.** Зап. от А.Г.Идрисова (1917) в г.Петропавловске.

**62з. Баламски көенә.** Зап. от Р.Х.Сеитовой (1933) и Р.Г.Хайбулиной (1946) в г.Семипалатинске.

**63. Күзләрең.** Зап. от З.Р.Табаевой (1940) в г.Алматы. Еще один образец творческого заимствования: мелодия имеет прямое сходство с русской песней «Когда б имел златые горы». Песня популярна среди татар, проживавших на территории Китая. Исполняется коллективно, группой чередующихся солистов, либо в диалогической форме.

**64. Айхайлүк.** Зап. от Х.Х.Галиакберовой (1948) в г.Алматы.

**65. Күбәләк.** Зап. от М.Г.Сиразитдиновой (1911) в г.Алматы.

**66. Сәрия.** Зап. от А.Сафитовой (1931) в г.Талгаре Алматинской области.

**67. Талы, талы.** Зап. от З.Шакирова (1930) в г.Алматы.

**68. Йолдызым, рушаным.** Зап. от Ш.Г.Темирбулатовой (1934) в г.Мамлютка СКО.

**69. Җизнәкәй.** Зап. от Ф.М.Валеевой (1927) в г.Капчагае Алматинской области.

**70. Чибәр егет.** Зап. от Х.А.Шагвалеевой (1909) в г.Мамлютка СКО.

# Содержание


**I. Озын көйләр** с.

№ 1. Аппагым, жанашым ........ 11
№ 2. Зөлхиҗҗә ........ 12
№ 3а. Уел. ........ 13
№ 3б. Уел ........ 13
№ 4. Гөлҗамал ........ 14
№ 5. Төфтиләү ........ 15
№ 6а. Зиләйлүк ........ 16
№ 6б. Зиләйлүк ........ 16
№ 7. Һаваларда йолдыз ........ 17
№ 8. Салкын чишмә ........ 17
№ 9. Үкенү ........ 18
№ 10. Сәгать чылбыры ........ 19
№ 11. Ашказар ........ 20
№ 12а. Кара урман ........ 21
№ 12б. Кара урман ........ 21
№ 12в. Кара урман ........ 22
№ 12г. Кара урман ........ 23
№ 13. Карурман аша ........ 25

**II. Бәетләр**

№ 14а. Сак-Сок ........ 26
№ 14б. Сак-Сок ........ 26
№ 15а. Сак-Сок ........ 27
№ 15б. Сак-Сок ........ 27
№ 15в. Сак-Сок ........ 28
№ 16. Ямщик бәете ........ 29
№ 17. Кара син алга ........ 29
№ 18а. Суга баткан Гайшә ........ 30
№ 18б. Суга баткан Гайшә ........ 30
№ 18в. Суга баткан Гайшә ........ 31
№ 19. Әткәемне кетәм әле ........ 31
№ 20. Уза яшь гомер ........ 32
№ 21. Солдат бәете ........ 33
№ 22. Мөнәҗәт ........ 34
№ 23. Мөнәҗәт ........ 34

**III. Салмак көйләр**

№ 24. Бишкүл ........ 35
№ 25а. Кошлар ........ 35
№ 25б. Кошлар көенә ........ 36
№ 26. Аппакай-алмакай. ........ 36
№ 27. Зәйнәбем ........ 37

№ 28. Шахтер көе ........ 37
№ 29. Шомыртым ........ 38
№ 30. Бәйбәтчә көе ........ 38
№ 31а. Алсу ........ 39
№ 31б.Алсу ........ 39
№ 32. Дим-дим ........ 40
№ 33. Авыл көе ........ 40
№ 34. Мәрфуга ........ 41
№ 35а. Рамай ........ 42
№ 35б. Рамай ........ 42
№ 36. Арча ........ 43
№ 37. Кызыл, кызыл ........ 43
№ 38. Уракчы кыз ........ 44
№ 39. Зәңгәр күлмәк ........ 44
№ 40. Умырзая ........ 45
№ 41. Авыл көе ........ 45
№ 42а. Галиябану ........ 46
№ 42б. Галиябану ........ 46
№ 42в. Галиябану ........ 47
№ 42г. Галиябану ........ 47
№ 43а. Саубуллашу көе ........ 48
№ 43б. Авыл көе ........ 48
№ 43в. Авыл көе ........ 49
№ 43г. Ялгыз каен ........ 49
№ 44а. Минзәлә ........ 50
№ 44б. Авыл көе ........ 50
№ 45а. Сарман ........ 51
№ 45б. Сарман ........ 51
№ 45в. Сарман ........ 52
№ 45г. Сарман ........ 52
№ 46а. Нурия ........ 53
№ 46б. Нурия ........ 53
№ 47. Илкәй ........ 54
№ 48а. Каз канаты ........ 54
№ 48б. Каз канаты ........ 55
№ 48в. Каз канаты ........ 55
№ 49. Вәгъдә ........ 55
№ 50. Хатлар язам ........ 56
№ 51. Рәйхан ........ 56
№ 52. Чугачак көе ........ 57
№ 53. Яңа тәфтиләү ........ 57
№ 54. Сагыш җыры ........ 58

**IV. Кыска көйләр**

№ 55. Җырлыйк әле ........ 59
№ 56. Бию көе ........ 59

№ 57. Бию көе ........ 60
№ 58. Туй җыры ........ 60
№ 59. Әпипә ........ 61
№ 60. Фәрхәнә ........ 61
№ 61. Урам көе ........ 62
№ 62а. Баламишкин ........ 63
№ 62б. Баламишкин ........ 63
№ 62в. Баламишкин ........ 64
№ 62г. Баламишкин ........ 64
№ 62д. Баламски ........ 65
№ 62е. Баламски ........ 66
№ 62ж. Петропавыл такмаклары ........ 66
№ 62з. Баламски көенә ........ 67
№ 63. Күзләрен ........ 68
№ 64. Айхайлүк ........ 69
№ 65. Күбәләк ........ 69
№ 66. Сәрия ........ 70
№ 67. Талы, талы ........ 70
№ 68. Йолдызым, рушаным ........ 71
№ 69. Җизнәкәй ........ 72
№ 70. Чибәр егет ........ 72

**V. Авторлык җырлар**

№ 71. Тәуге сөю. Г.Таминдаров, Р.Гузаиров ........ 73
№ 72. Ашкынам мин туган ягыма. Г.Таминдаров, Р.Гузаиров ........ 74
№ 73. Кар сулары. Г.Таминдаров, Р.Гузаиров ........ 74
№ 74. Яшьлегемнең таңнары. Г.Таминдаров, Р.Гузаиров ........ 75
№ 75. Чабата. Г.Таминдаров, Р.Гузаиров ........ 76
№ 76. Матур булсын киләчәк. Г.Таминдаров, Р.Абдусалямов ........ 77
№ 77. Безнең «Сарман». Г.Таминдаров, Р.Гузаиров ........ 77
№ 78. Җилләр исә. Г.Таминдаров, Р.Гузаиров ........ 78
№ 79. Бер яшьлектә, бер картлыкта. Г.Таминдаров, Р.Гузаиров ........ 78
№ 80. Нурия. Г.Таминдаров, Р.Гузаиров ........ 79
№ 81. Сагынам. Г.Таминдаров, Р.Гузаиров ........ 80
№ 82. Минем мәхәббәтем. Ш.Сагаутдинов, Ш.Сагаутдинов ........ 81
№ 83. Мәхәббәт сүрелми. ШСагаутдинов ........ 82
№ 84. Язгы ташкын. Э.Гузаирова, Р.Гузаиров ........ 83
№ 85. Ромашкалар. Э.Гузаирова, Муса Җәлил шигыренә ........ 83
№ 86. Көтәм сине. Э.Гузаирова ........ 84
№ 87. Алматы турында җыр. Э.Гузаирова, Р.Гузаиров ........ 85
№ 88. Үткән мәхәббәт. Э.Гузаирова, Р.Гузаиров ........ 86
№ 89. Монсу. Э.Гузаирова, Р.Гузаиров ........ 87

КОММЕНТАРИИ ........ 88